2. После принятия проекта Устава Района, проекта решения о внесении изменений и дополнений в настоящий Устав в первом чтении указанный проект направляется Главой Района депутатам Совета Района, иным субъектам права правотворческой инициативы, указанным в пункте 1 статьи 69 настоящего Устава, для внесения поправок.

3. Устав Района, решение Совета Района о внесении изменений и дополнений в Устав принимаются большинством в две трети голосов от установленной численности депутатов Совета Района.

**Статья 107. Порядок вступления в силу Устава Района, решения о внесении изменений и дополнений в настоящий Устав**

1. Устав Района, решение Совета Района о внесении изменений и дополнений в настоящий Устав подлежат государственной регистрации в территориальном органе уполномоченного федерального органа исполнительной власти в сфере регистрации уставов муниципальных образований в порядке, установленном федеральным законом»;

2. Устав Района, решение Совета Района о внесении изменений и дополнений в настоящий Устав после их государственной регистрации подлежат официальному опубликованию (обнародованию) в течение семи дней со дня поступления из территориального органа уполномоченного федерального органа исполнительной власти в сфере регистрации уставов муниципальных образований»;

3. Изменения и дополнения, внесенные в Устав Района и изменяющие структуру органов местного самоуправления Района, полномочия органов местного самоуправления (за исключением полномочий, срока полномочий и порядка избрания выборных должностных лиц местного самоуправления), вступают в силу после истечения срока полномочий Совета района, принявшего муниципальный правовой акт о внесении в Устав Района указанных изменений и дополнений

4. Изменения и дополнения, внесенные в Устав Района и предусматривающие создание контрольно-счетного органа Района, вступают в силу в порядке, предусмотренном действующим законодательством.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**№ 9-77, 14нче март 2016нчы ел Карары**

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставын кабул итү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 44нче маддәсенә,”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 7нче маддәсенә туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставын №1 Кушымта белән килештереп кабул итергә.
2. Әлеге карарны кануннар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт регистрациясенә җибәрергә.
3. Бу карар көченә кергән көннән көчен югалткан дип санарга:

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставын кабул итү турында “ 10нчы декабрь, 2005нче ел, №18 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 10.07.2007 , № 16-171 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 27.05.2008 , № 27-280 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 28.10.2008 , № 32-328 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 14.04.2009 , № 37-374 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 25.08.2009 , № 40-407 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 31.08.2010 , № 52-516 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр

Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 20.12.2010 , № 5-56 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 01.06.2011 , № 11-108 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 12.12.2011 , № 19-186 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 04.04.2012 , № 25-237 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 29.04.2013 , № 37-361 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 20.06.2014 , № 47-470 карары;

- Югары Ослан муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлекләр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында “ 02.03.2015 , № 56-541 карары;

4. Әлеге карарны кануннар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт регистрациясеннән соң Татарстан Республикасы хокук мәгълуматы рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы 14нче март 2016нчы ел № 9-77 карарына
Кушымта №1

# Татарстан Республикасы
# Югары Ослан муниципаль районы
# Уставы
## Iнче бүлек. ГОМУМИ нигезләмәләр

### 1нче маддә. Муниципаль район һәм аның статусы

1. Татарстан Республикасы канунына туры китереп "Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлегенә муниципаль район статусы бирелгән.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме – "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы"(алда текст буенча-Район).

### 2нче маддә. Районның территориаль төзелеше

"Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына түбәндәге муниципаль берәмлекләр керә:

шәһәр җирлеге статусы бирелгән һәм Иннополис шәһәреннән һәм аның янәшәсендәге территорияләрдән торган "Иннополис шәһәре";

Олы Мәми саласы (административ үзәк), Заборная Поляна авылы, Ивановское посёлогы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Олы Мәми авыл җирлеге ";

Татар Борнашы саласы (административ үзәк), Юматово саласы, Гаврилково, Ломовка, Тихий Плёс, Каинка авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Татар Борнашы авыл җирлеге";

Мулланур Вахитов исемендәге авыл (административ үзәк), Ташёвка саласы, Ватан, Гребени авыллары, Бакча-Сарай посёлогы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Вахитов авыл җирлеге";

Введенский Бистәсе саласы (административ үзәк), Елезаветино, Медведково, Савино авыллары, Восточная Звезда, "Балалар санаториясе", Петропавловская Слобода посёлоклары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Введенский Бистәсе авыл җирлеге";

Югары Ослан саласы (административ үзәк), Студенец авылы, Киров исемендәге посёлок һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Югары Ослан авыл җирлеге";

Канаш авылы (административ үзәк), Нижнее Озеро, Йолдыз авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Канаш авыл җирлеге";

Килди саласы (административ үзәк), Федяево саласы, Уланово, Харино авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Килди авыл җирлеге";

Карагуҗа саласы (административ үзәк), Егидерево, Патрекеево авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган "Карагуҗа авыл җирлеге";

Куралово саласы (административ үзәк), Рус Борнашы саласы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Куралово авыл җирлеге”;

Мәйдан саласы (административ үзәк), Ясная Поляна авылы, Теньки урманчылыгы посёлогы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Мәйдан авыл җирлеге”;

Макыл саласы (административ үзәк), Рус Макылы, Сеитово салалары, Исаево, Клянчино, Татар Макылы авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Макыл авыл җирлеге”;

Яр буе Морквашы саласы (административ үзәк), Урман Морквашы саласы, Покровка авылы, Никольский, Пустой Морквашы, Пятидворка, Десятидворка посёлоклары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Яр буе Морквашы авыл җирлеге”;

Түбән Ослан саласы (административ үзәк), Воробьёвка авылы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Түбән Ослан авыл җирлеге”;

Иске Рус Мәмәтхуҗасы саласы (административ үзәк), Яңа Рус Мәмәтхуҗасы, Татар Мәмәтхуҗасы авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге”;

Октябрь посёлогы (административ үзәк), Ключищи, Матюшино, Яңа Болгар салалары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Октябрь авыл җирлеге”;

Печищи саласы (административ үзәк), Захваткино авылы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Печищи авыл җирлеге”;

Соболевский саласы (административ үзәк), Чулнаниха саласы, Карамышиха авылы һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Соболевский авыл җирлеге”;

Шылангы саласы (административ үзәк), Берек, Нариман авыллары, Кызыл Байрак, Яңа Юл посёлоклары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Шылангы авыл җирлеге”;

Ямбулат саласы (административ үзәк), Кызыльяр, Кресниково авыллары һәм янәшәсендәге территорияләрдән торган “Ямбулат авыл җирлеге”;

“Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең административ үзәге булып Югары Ослан саласы тора.

3. Районның чикләре “Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы” һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләренең чикләрен билгеләү һәм статусы турында” 31.01.2005 ел, №19-ЗРТ Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән.

4. Район чикләре, районның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлекләр арасында әһәмиятле мәсьәләләрне чишү мөмкинлекләрен тудыру кирәклекне истә тотып, шулай ук федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары тарафыннан әлеге органнарга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен район территориясендә башкару өчен билгеләнгән.

5. Районның чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору кануннар билгеләгән тәртиптә, Татарстан Республикасы кануннары тарафыннан башкарыла.

**3нче маддә. Районның рәсми символлары**

1. Район тарихи, мәдәният һәм башка җирле гореф-гадәтләрне һәм үзенчәлекләрне чагылдырган үз гербына ия.

2. Гербның тасвирламасы Район Советының норматив хокук актлары белән раслана.

3. Гербның сурәте Районның җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге затларның һәм органнарның мөһерләрендә, рәсми документларында һәм бланкларында, Район Советы утырышлар залында, Район Башлыгының һәм Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең эш кабинетларында урнаштырыла. Гербны башка рәсми кучерелмә очраклары Район Совет карары белән билгеләнә.

4. Район Гербы федераль кануннар буенча билгеләнгән тәртиптә дәүләт регистрациясе узарга тиеш.

5. Районның шулай ук үз Флагы һәм Гимны була ала.

**4нче маддә. Халыкның Районда җирле үзидарәне тормышка ашыруга хокукы**

1. Районда җирле үзидарәне тормышка ашыру аның халкы тарафыннан җирле референдумда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы һәм туры теләк белдерүнең башка формалары белән, шулай ук әлеге Устав белән каралган җирле үзидарәнең сайлау һәм башка органнары аша тормышка ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне тормышка ашыруда җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәт һәм дәүләт хезмәтендәге хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, иҗътимагый оешмаларда булуына карамастан, бәйсез рәвештә дә, үзләренең вәкилләре аша да тигез хокукка ия.

3. Һәр кеше турыдан-туры җирле үзидарә органнарына һәм Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затларга мөрәҗәгать итергә, җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында мәгълумат алырга хаклы.

4. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге затлары һәркемгә турыдан-туры аның хокуклары һәм ирегенә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга мөмкинлек бирергә бурычлы, шулай ук гражданнарга, канун белән башка нәрсә каралмаган булса, Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм ышанычлы мәгълуматларны алырга мөмкинлек бирергә тиеш.

5. Районның җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълумат чаралары аша һәм башка юл белән халыкны Район һәм аның аерым территорияләре үсешенең иң мөһим мәсьәләләре турында, иҗтимагый өстенлекләр турында, экология торышы турында, җәмәгать тәртибен саклау торышы турында һәм табигатьтәге һәм техноген характердагы гадәттән тыш чаралар турында даими хәбәр итеп тора.

6. Гражданнар, әгәр алар кануннарга каршы килсә, хокукларын, ирегенһәм гражданнарның законлы мәнфәгатьләрен бозса, хокук актларын, Районның җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт хезмәтендәге затларның гамәлләре һәм гамьсезлекләрен судка шикаять бирергә хокуклы.

**5нче маддә. Район җирле үзидарә органнарының төзелеше**

1. Районның җирле үзидарә органнарының төзелешенә, әлеге Уставка туры китереп барлыкка килгән, Район Советы, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты, башка җирле үзидарә органнары керә.

2. Районның җирле үзидарә органнарының төзелешенә үзгәрешләр әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән тормышка ашырыла.

**6нчы маддә. Районның аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләре**

1. Районның аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль район бюджеты проектын төзү һәм карап чыгу, муниципаль район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тотуны тормышка ашыру, муниципаль район бюджеты үтәлеше турында отчётны төзү һәм раслау;

2) муниципаль районның җирле салым һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) муниципаль районның муниципаль милегендә булган мөлкәткә ия булу, аны куллану һәм аннан файдалану;

4) муниципаль район чикләрендәге торак пунктларда электор-, җылылык- һәм газ белән тәэмин итүне оештырырга;

5) Россия Федерациясе кануннарына туры китереп, аерым бер урын өчен әһәмияте булган, торак пунктлардан башка муниципаль район чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, аерым бер урын өчен әһәмияте булган, торак пунктлардан башка муниципаль район чикләрендә автомобиль юлларының торышына муниципаль контрольне тормышка ашыру, аларда юл хәрәкәте иминлеген булдыру, шулай ук автомобиль юлларын куллану өлкәсендә башка вәкаләтләрне һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыру;

6) халыкка транспорт уңайлыкларын булдыру өчен һәм муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру;

7) террорчылыкка һәм экстремизмга каршы профилактик чараларда катнашу, шулай ук муниципаль район территориясендә террорчылык һәм экстремизм нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) булдырмый калу;

8) муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телен һәм мәдәниятен үстерүгә ярдәм итү, милләтләр арасында килешүне ныгытуга юнәлтелгән чараларны булдыру һәм тормышка ашыру, милли азчылыкны тәшкил иткән халыкларның хокукларын тормышка ашыру, күчеп килгән халыкларның иҗтимагый һәм культуралы җайлашуын, милләтара (этникара) низахларны булдырмый калуны тәэмин итү;

9) муниципаль район территориясендә гадәттән тыш чараларны кисәтү һәм булдырмый калуда катнашу;

10) муниципаль район территориясендә муниципаль полиция тарафыннан җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

11) муниципаль районның административ бүлегендә участок полициясе вәкиле вазифасын башкаручы хезмәткәргә эш өчен бина бүлеп бирү;

12) 2017нче елның 1нче гыйнварына кадәр участок полициясе вәкиле вазифасын башкаручы хезмәткәргә, һәм аның гаиләсенә, хезмәткәр әлеге вазифасын башкарган вакытка, торыр урын бирү;

13) тирә як мохитны саклау буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру;

14) муниципаль белем бирү оешмаларында һәркемгә бушлай төп белем бирү программалары буенча мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры китереп эшләнгән төп белем бирү программаларын тормышка ашыруны финанслау вәкаләтеннән кала ), муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары балаларга өстәмә белем бирүне финанслаудан кала), балаларны карауны тормышка ашыру буенча шартлар тудыру, шулай ук каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру;

15) муниципаль район территориясендә, (Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган, халыкка медицина ярдәме күрсәтү, аерым территория халкына медик-санитар функцияләрне тормышка ашыручы башкарма хакимият органнарына караган оешмаларда күрсәтелгән җирлек территорияләреннән кала) гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасына туры китереп халыкка медицина ярдәме күрсәтүгә шартлар булдыру;

16) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), ташу, эшкәртү, юкка чыгару, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлеген оештыруда катнашу;

17) муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын раслау, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән документларны раслау, муниципаль район территориясендә башкарылган төзелешне мәгълумати система белән тәэмин итүне булдыру, муниципаль район чикләрендә муниципаль кирәк-яраклар өчен җир кишәрлекләрен резервлау һәм алу;

18) реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларын раслау, муниципаль район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга рөхсәт бирү, муниципаль район территориясендә рөхсәтсез урнаштырган реклама конструкцияләренә рөхсәт бирүне, ”Рекламалар турында”13нче март, 2006нчы ел, №38-ФЗ Федераль канунына туры китереп, юкка чыгару, сүтү турында боерык бирү ;

19) муниципаль архивны, җирлекләрнең архив фондын саклауны кертеп, оештыру һәм карап тору;

20) муниципаль район территориясендә җирлекара күмү урыннарын карап тору, ритуаль хезмәтләрне оештыру;

21) муниципаль район составына кергән җирлекләрдә элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә шартлар тудыру;

22) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне җирлекара китапханәләр тарафыннан оештыру, аларның китапханә фондын тулыландыру һәм торышын тәэмин итү;

23) муниципаль район составына кергән җирлекләрдә ял һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә шартлар тудыру;

24) муниципаль район составына кергән җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерүгә шартлар тудыру;

25) муниципаль район милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклау, файдалану һәм популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан, бу урын өчен әһәмиятле булган (муниципаль) мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклау;

26) муниципаль район бюджеты хисабына муниципаль район составына кергән җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү;

27) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыру һәм тормышка ашыру, муниципаль район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау;

28) муниципаль район территориясендә бу урын өчен әһәмиятле булган дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны оештыру, шулай ук саклана торган табигый территорияләрне саклау һәм куллану өлкәсендә муниципаль контрольне тормышка ашыру;

29) муниципаль район территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең мобилизацион хәзерлекләре буенча чаралар оештыру һәм тормышка ашыру;

30) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны тормышка ашыру;

31) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы производствасын үстерү буенча шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы производствасы, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышу, иҗимагый ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйриячелек эшчәнлегенә һәм үз ирке белән эшләүчеләргә ярдәм күрсәтү;

32) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерүгә шартлар булдыру, муниципаль районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру;

33) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм уздыру;

34) Россия Федерациясенең сулар турында канунында билгеләнгән чикләрдә су объектлары хосусый милек иясе вәкаләтләрен тормышка ашыру, шәхси һәм көнкүреш кирәк-яраклары өчен гомуми кулланышта булган су объектларын куллану кагыйдәләрен урнаштыру, гомуми кулланышта булган су объектларына һәм аларның яр буена гражданнарның иркле керүен тәэмин итү;

35) муниципаль урман контролен тормышка ашыру;

36) муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү, федераль кануннарга туры китереп ясалма җир кишәрлекләре булдыру турында килешү төзүгә хокук алуга ачык аукцион үткәрү;

37) муниципаль район чикләрендә ришвәтчелеккә каршы тору буенча чараларны тормышка ашыру;

38) адреслау объектларына адреслар бирү, адресларны юк итү, үзгәртү, урам-юл челтәрләре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларыннан кала, региональ автомобиль юллары яки муниципальара әһәмияткә ия булган юллардан кала ), муниципаль районның авылара территорияләре чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәрен бирү, шул исемнәрне үзгәртү, юк итү, дәүләт адреслар реестрында мәгълуматны урнаштыру;

39) “Дәүләт күчемсез милек кадастры турында” 24нче июль, 2007нче ел, №221-ФЗ Федераль канунына туры китереп комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территория планы картасынраслау.

2.Муниципль районның аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләренә шулай ук “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” № 131-ФЗ Федераль канунының 14нче маддәсендә каралган, бу федераль канун һәм Татарстан Респубiиксы кануннары белән авыл җирлекләренә беркетелмәгән мәсьәләләр керә.

3. Районның җирле үзидарә органнары муниципль район составына кергән аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән яраклаштырып, муниципаль район бюджетыннан шушы җирлекләр бюджетына бирелгән бюджетара трансфертлар хисабына, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында килешү төзергә хокуклы.

Районның җирле үзидарә органнары муниципль район составына кергән аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары муниципаль районның җирле үзидарә органнары белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән яраклаштырып, муниципаль район бюджетыннан шушы җирлекләр бюджетына бирелгән бюджетара трансфертлар хисабына, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында килешү төзергә хокуклы.

**7нче маддә. Районның җирле үзидарә органнарының Районның аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләргә карамаган мәсьәләләрне чишүгә хокуклары**

1. Районның җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Район музейларын төзергә;

2) опека һәм тәрбиячелек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнашырга;

3) Район территориясендәге җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле булган эшчәнлекне тормышка ашыруда шартлар булдырырга;

4) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм Район территориясендә милләтара бәйләнешләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга булышлык итергә;

5) 2008нче елның 31нче декабренә аларның карамагында булган муниципаль югары белем бирү оешмаларының оештыручы функцияләрен тормышка ашырырга;

6) туризмны үстерүгә шартлар тудырырга;

7) кеше хокукларын яклаучы иҗтимагый контрольне тормышка ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтергә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга булышлык итергә;

8) инвалидларның иҗтимагый оешмаларына ярдәм күрсәтергә, шулай ук “Россия Федерациясендә инвалидларны иҗтимагый яклау турында” 24нче ноябрь, 1995нче ел, №181-ФЗ Федераль канунына яраклаштырып бөтенроссия иҗтимагый инвалидлар оешмалары төзегән организацияләргә ярдәм итергә;

9) “Донорлык һәм аның компонентлары турында ” Федераль канунда каралган чараларны тормышка ашырырга;

10) федераль кануннарда билгеләнгән шартлар һәм тәртип буенча оешмаларның хезмәт күрсәтүен бәйсез бәяләү тәртибен оештыру өчен шартлар тудырырга.

2. Районның җирле үзидарә органнары әлеге маддәнең 1нче өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне, әгәр бу катнашу федераль кануннар белән каралган булса, башка дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруда катнашырга хокуклы (“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунына туры китереп аларга тапшырылмаган булса), шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең, дәүләт власте органнарының җирле үзидарә органнары компетенциясенә карамаган һәм федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән аларның компетенциясеннән алып ташланмаган башка сорауларны чишәргә хаклы, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән , бюджетара трансфертлардан кала, район бюджеты кереме хисабына гына, һәм өстәмә норматив аерым бирелгән сумма буенча налог кереме хисабына чишәргә хаклы.

### 8нче маддә. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы

1. Районның җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешен оештыру, муниципаль берәмлекләрнең уртак кызыксынуын гәүдәләндерү һәм яклау максатыннан Район Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы эшендә катнаша, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең башка оешмалары эшендә катнашырга хокуклы.

2. Район җирле үзидарә органнары тарафыннан әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү өчен финанс, материаль һәм башка ресурсларны берләштерү максатыннан, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән муниципальара оешмалар барлыкка килә, хуҗалык җәмгыятьләре һәм башка муниципальара оешмалар барлыкка килә, федераль кануннарга һәм Район Советының норматив хокук актларына туры китереп шартнамәләр һәм килешүләр төзелә ала. Күрсәтелгән муниципальара оешмаларга Район җирле үзидарә органнары вәкаләтләре бирелми.

### 9нчы маддә. Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән үзара бәйләнеше

Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт власте органнары белән үзара бәйләнеше түбәндәгеләр аркылы тормышка ашырыла:

1) Районның җирле үзидарә органнарының Районның иҗтимагый-икътисад үсешенә юнәлтелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;
2) Районның җирле үзидарә органнары белән дәүләт власте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;
3) даими яки вакытлы координацион, консультатив, киңәшләшүче башка эшче органнар төзү;
4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Район Советының законнар чыгаруга хокук инициативасы;
5) кануннарда билгеләнгән башка үзара бәйләнеш формалары.

## IIнче бүлек. Район халкы тарафыннан җирле үзидарәне тормышка ашыру һәм Район халкының җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуы

### 10нчы маддә. Район халкы тарафыннан турыдан –туры җирле үзидарәне тормышка ашыру һәм Район халкының җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуы формалары

Район халкы турыдан –туры җирле үзидарәне тормышка ашыра һәм җирле үзидарәне тормышка ашыруда түбәндәге формаларда катнаша:
1) җирле референдум;
2) җирле үзидарә сайлаган дәүләт хезмәтендәге зат, җирле үзидарә сайлау органы вәкиле, депутат чакыруы буенча тавыш бирү, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;
3) гражданнарның иҗади хокук инициативасы;
4) иҗтимагый территориаль үзидарә;
5) халык алдында тыңлаулар;
6) гражданнар җыелышы;
7) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);
8) гражданнарны сораштыру;
9) иң әһәмиятле булган мөһим сорауларны халык белән тикшерү;
10) җирле үзидарә органнарына халыкның мөрәҗәгате;
11) иҗтимагый (консультатив) советлар оештыру;
12) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы кануннарына каршы килми торган башка формалар.

### 11нче маддә. Җирле рефререндум

1. Җирле референдум, федераль кануннарга һәм Татарстан Республикасы кануннарына туры китереп, әһәмиятле булган мәсьәләләрне турыдан-туры Район халкы тарафыннан хәл итү максатыннан уздырыла.
2. Җирле референдум Районның барлык территориясендә уздырыла.
3. Җирле референдумда җирле референдумда катнашу хокукы булган Район халкы катнаша. Җирле референдумда гражданнар гомуми тигез һәм туры теләк белдерү нигезендә яшерен тавыш бирүдә катнаша.
4. Җирле референдумны уздыру турында карар Район Советы тарафыннан түбәндәге инициативалар буенча кабул ителә:
1) җирле референдумда катнашу хокукы булган гражданнар;

2) сайлау оешмасы, уставыда сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашу каралган  һәм федераль кануннар билгеләгән тәртиптә һәм срокта теркәлгән башка иҗтимагый оешма;
3) бергә тәкъдим ителгән, Район Советы һәм Район Башкарма комитеты Җитәкчесе.
5. Җирле референдумны билгеләүгә шартлар булып  гражданнар, сайлау оешмалары, башка иҗтимагый оешмалар инициативасы буенча әлеге инициативаны хуплап, федераль кануннарга туры китереп, Татарстан территориясендә теркәлгән, референдумда катнашучыларның 5 проценттан күбрәк булмаган санда җыелган имзалар тора.
6. Җирле референдумны уздыру турында Район Советы белән  Район Башкарма комитеты Җитәкчесе берлектә тәкъдим иткән инициатива Район Советы карары һәм  Район Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән теркәлә. Әлеге инициативаны тәкъдим итү тәртибе Район Советы норматив хокук актлары белән билгеләнә.
7. Район Советы җирле референдумны, Район Советына алар нигезендә җирле рефрендум билгеләнгән документлар килгән көннән 30 көн эчендә билгели.
8. Җирле референдумда тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).
9. Җирле референдумда кабул ителгән карар Район территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш һәм башка дәүләт власте органнары, аларның дәүләт хезмәтендәге затлары яки Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан расланырга тиеш түгел.
10. Районның җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен, әлеге Уставта билгеләнгән алар арасындагы вәкаләтләр бүленешенә туры китереп, тәэмин итә.
11. Җирле референдумны уздыру турында һәм җирле референдумда кабул ителгән карар, федераль кануннарга туры китереп суд тәртибендә шикаять бирә ала .
12. Җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына төп гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында” Федераль канун белән һәм “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Кануны белән җайга салына.

**12нче маддә. Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп коруга  халыкның ризалыгын алу максатыннан уздырыла.
2. Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү бөтен Район территориясендә уздырыла, яки аның территориясенең аерым өлешләрендә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003.
№ 131-ФЗ Федераль кануны билгеләгән очракта уздырыла.
3. Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Район Советы тарафыннан һәм федераль кануннар һәм “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Кануны билгеләгән тәртиптә,

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003. № 131-ФЗ Федераль канунында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнә.

4. Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

**13нче маддә. Халыкның иҗади хокук инициативасы**

1. Район халкы әлеге Устав һәм Район Советы норматив хокук актлары билгеләгән тәртиптә иҗади хокук инициативасына хокукы бар.

2. Иҗади хокук инициативасы белән сайлау хокукы булган Район халкының 3 проценттан ким булмаган актив сайлау хокукы булган гражданнар төркеме чыга ала.

3. Иҗади хокук инициативасын тормышка ашыру максатларында Район халкы хаклы:

иҗади хокук инициативасын тикшерү һәм күрсәтү буенча халыкның яшәү һәм эш урыннары буенча гражданнар җыелышлары һәм башка коллектив чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

иҗади хокук инициативасын күрсәтүгә ярдәм итү өчен имзалар җыю буенча инициатив төркемнәр оештыру;

иҗади хокук инициативасын күрсәтүгә ярдәм итү өчен Район халкыннан имзалар җыю һәм агитация алып баруны кануннарга каршы килми торган юллар белән үткәрү.

4. Районның җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге затлар һәм органнар Район халкына иҗади хокук инициативасын тормышка ашыруда булышлык итәргә тиеш.

5. Гражданнарның иҗади хокук инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проекты, әлеге Устав белән билгеләнгән үзләренең компетенцияләре кысаларында Район Башлыгы яки Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан Район Советының ачык утырышында аны керткәннән соң өч ай эчендә каралырга тиеш.

6. Гражданнарның иҗади хокук инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын караган вакытта гражданнарның инициатив төркем вәкилләренә үзләренең позицияләрен күрсәтеп бирергә мөмкинчелек булдырылырга тиеш.

7. Гражданнарның иҗади хокук инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын карап чыгу процедурасы Район Советы Регламентына, Район Башлыгының, Район Башкарма комитетының норматив хокук актларына туры китереп билгеләнә.

8. Гражданнарның иҗади хокук инициативасын тормышка ашыру вакытында кертелгән муниципаль хокук актлар проектын карап чыгу нәтиҗәләре буенча кабул ителгән мотивлаштырылган карары рәсми рәвештә язма формада аны керткән гражданнар төркеменә җиткерелергә тиеш.

**14нче маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә**

1. Районда территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан гражданнарның җыелышлары һәм конференцияләр уздыру юлы белән, шулай ук  территориаль иҗтимагый үзидарә органнары оештыру белән тормышка ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яшәгән түбәндәге территорияләр кысаларында  тормышка ашырыла: күпфатирлы торак йортлар подъездында; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булмаган торак пункт;  гражданнар яшәгән башка территорияләр .

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылган территория чикләре элеге җирлекнең территориясендә яшәгән халык  сайлап куйган органнар тарафыннан билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә тормышка ашырылган территория башка охшаш территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә аның уставы кысаларында юридик зат була ала һәм комерцияле булмаган оешманың оештыру-хокук формасында дәүләт регистрациясен узарга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнә:

1) ул тормышка ашырылган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максаты, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының формалашу тәртибе, вәкаләтләре туктатылу, хокуклары һәм бурычлары, органнарының вәкаләтлек вакыты;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук әлеге мөлкәтне һәм финанс чараларын  куллану һәм эш алып бару тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең туктатылу тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, конференцияләр аның уставына туры китереп чакырыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру  мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, өчтән бер өлешеннән ким булмаган уналты яше тулган аның территориясе халкы катнашса, тулы хокуклы булып санала. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру  мәсьәләләре буенча гражданнарның конференцияләре гражданнар җыелышында өчтән бер өлешеннән ким булмаган уналты яше тулган аның территориясе халкы тарафыннан сайланган делегатларның өчтән ике өлешеннән ким булмаган кеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген оештыручы гражданнарның конференцияләре, җыелышлары махсус вәкаләтлекләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнарының сметасын һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының эшчәнлеге турында хисапны карап чыгу һәм раслау.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) шушы территориядә яшәүче халык ихтыяҗларын чагылдыра;

2) гражданнарның конференцияләре, җыелышларында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итә;

3) торак фондын тоту буенча хуҗалык эшчәнлеге, территорияне төзекләндерү , шушы территориядә яшәүче халыкның иҗтимагый-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән башка хуҗалык эшләрен, шушы гражданнарның акчаларына да, җирле үзидарә органнары белән төзегән килешү нигезендә җирле бюджет акчаларын кулланып та тормышка ашыра ала ;

4) Район Советына, Район Башлыгына һәм Район Башкарма комитетына бу органнар һәм җирле үзидарә органнарының, күрсәтелгән актларны кабул итү аларның компетенциясендә булган дәүләт хезмәтендәге затлар тарафыннан һичшиксез карап чыгарга тиешле муниципаль хокук актларының проектларын кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру җирлек уставы һәм (яки) җирлекнең сайлап куелган органының норматив хокук актлары белән билгеләнә .

Җирле бюджеттан тиешле акчаны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе җирлек уставы белән һәм (яки) җирлекнең сайлап куелган органының норматив хокук актлары белән, Район Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

**15нче маддә. Ачык тыңлаулар**

1. Әһәмиятле мәсьәләләр буенча муниципаль хокук актлары проектларын тикшерү өчен Район халкы катнашында Район Советы, Район Башлыгы тарафыннан ачык тыңлаулар уздырылырга мөмкин.

2. Ачык тыңлаулар халык, Район Советы һәм Район Башлыгы инициативасы буенча уздырыла.

Район Советы яки халык инициативасы буенча уздырылган ачык тыңлаулар, Район Советы тарафыннан, ә Район Башлыгы инициативасы буенча- Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Ачык тыңлауларга түбәндәгеләр кертелә:

1) Россия Федерациясе Конституциясе белән туры китереп әһәмиятле булган мәсьәләләрне һәм вәкаләтләрне китерү максатыннан аларны чишү буенча Уставка үзгәрешләр кертү очракларыннан кала, Район уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук акты проекты, федераль кануннар;

2) Район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Район үсеше планнары проектлары һәм программалары, җирне куллау һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияләрне планлаштыру проектлары һәм территорияне мижалау проектлары, шулай ук шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлекләрен һәм капитал төзелеш объектларын куллануга рөхсәт бирү мәсьәләләре, рөхсәт ителгән төзелешнең

тиешле параметрларыннан читкә китү мәсьәләләре, капитал төзелеш объектларын яңартып төзү;

4) Федераль канунның 13нче маддәсенә туры китереп муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлек халкының гражданнар җыенында тавыш бирү юлы белән ризалыгын алу кирәк булган очрактан кала, Районны үзгәртеп кору мәсьәләләре;

5) җирле салымнар һәм җыемны билгеләү мәсьәләләре;

6) расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаган очракта, бер төрдәге рөхсәт ителгән җир кишәрлекләрен һәм капитал төзелеш объектларын кулланулы икенче шундый төр куллануга үзгәртү.

4. Ачык тыңлаулар уздыру турында хокук акты, канун, районның муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән срокларда, Районның дәүләт хезмәтендәге заты яки тиешле органнар тарафыннан муниципаль норматив хокук актлары проектларын карап чыккан көннән кабул ителә.

5. Ачык тыңлаулар уздыру турында карар, аларны уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, һәм ачык тыңлауларга кертелгән шушы муниципаль норматив хокук акты канунда каралган срокларда бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Ачык тыңлаулар уздыру турында карарны бастырып чыгарган көннән алып аны уздыру көненә кадәр Район халкы Район Башлыгына язма рәвештә ачык тыңлауларга кертелгән мәсьәлә буенча тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен, шул исәптән ачык тыңлауларга кертелгән норматив хокук актлары проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәрен юнәлтергә хокуклы. Район Башлыгы кертелгән тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне гомумиләштерә. Әлеге тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

7. Ачык тыңлаулар канун, районның муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән срокларда уздырыла. Ачык тыңлаулар чакырылган белгечләр, экспертлар, кызыксынган затлар катнашында уза. Ачык тыңлауларда Районның теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

8. Ачык тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре буенча, ачык тыңлауларга куелган муниципаль норматив хокук акты проектын кабул итү аларның компетенцияләренә караган җирле үзидарә органнары һәм Районның дәүләт хезмәтендәге затлар тарафыннан тикшерелергә тиешле тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Ачык тыңлауларның нәтиҗәсе муниципаль норматив хокук акты һәм канунда каралган срокларда бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Район Советы раслаган ачык тыңлаулар турында Кагыйдәнамә белән билгеләнә.

**16нчы маддә. Гражданнар җыелышы.**

1. Әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерү өчен, халыкны Районның җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге затлар һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән таныштыру өчен, территориаль иҗтимагый үзидарәнең тормышка ашыру өчен Район территориясе бүлегендә гражданнар җыелышлары уздырыла ала. Гражданнар җыелышлары

микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар, Районның торак пунктларында уздырыла ала.

2. Гражданнар җыелышлары халык теләге буенча, Район Советы, Район Башлыгы инициативасы буенча , шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Район Советы яки Район Башлыгы инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар җыелышлары Район Советы һәм Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар җыелышлары Район Советы тарафыннан, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, җыелышта катнашырга хокуклары булган шушы территориядә яшәүче халык санының 10 процентыннан ким булмаган гражданнар төркеме, шушы территориядә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренең язмача тәкъдимнәре буенча билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турында тәкъдим карап чыгарга тиешле сораулар, җыелышны үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълуматны үз эченә алырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланырга тиеш, әгәр җыелышны үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать иткән булса- һәрберсенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны, адресы күрсәтелгән бу гражданнар тарафыннан имзалана.

Район Советы гражданнар җыелышын үткәрү турында кертелгән тәкъдимне үзенең якындагы утырышында карый.

Район Советы гражданнар җыелышын үткәрүне максатчан булмаган сәбәпләр буенча кире кагырга тиеш түгел.

5. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру максатыннан территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында һәм тикшерүгә куелган сораулар турында әлеге территория халкына җыелышны уздырганчы җиде көн алдан массакүләм мәгълумат чараларын, почта кәгазьләрен, фатирларны (ишегалларын) йөреп, игъланнар һәм башка чараларны кулланып хәбәр ителергә тиеш.

Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм үткәрүне Район Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә 18 яше тулган, шушы территориядә яшәүче, сайлау хокукы булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны, Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе кысаларында муниципаль сайлаулар үткәргәндә кулланылган тору урыны һәм яшәү урыны буенча регистрация теркәүе мәгълуматлары нигезендә билгеләнә.

Гражданнар җыелышы, җыелышта катнашу хокукы булган гражданнар санының өчтән бер өлешеннән ким булмаган кеше анда катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Җыелыш карары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затларга мөрәҗәгать кабул итә ала, шулай ук Район җирле үзидарә органнарының дәүләт

хезмәтендәге затлар белән үзара бәйләнештә гражданнар җыелышын тәкъдим итүче затларны сайлый ала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча уздырылган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән аларның компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышы белән кабул ителгән карарларны, аларның компетенцияләренә караган мөрәҗәгатьләрдә булган сорауларны чишү каралган җирле үзидарә органнары һәм Район җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затлар карап чыгарга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын әзерләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль канун, әлеге Устав һәм Район Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышының нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**17нче маддә. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)**

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерү кирәк булган очракта һәм барлык Район халкы вәкилләренең фикерен ачыклау өчен үткәрелә.

Район территориясендә яшәүче халык арасыннан булган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), гражданнар җыелышын чакыру кыенлашкан вакытта, шул исәптән шушы территориядә яшәүче гражданнар җыелышында катнашырга хокукы булган халык саны 300 кешедән артып китсә, үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтен тормышка ашыра.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык теләге буенча, Район Советы, Район Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә. Район Советы яки Район Башлыгы инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Район Советы һәм Район Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы буенча үткәрелгән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Район Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) сайланган делегатларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашкан делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышы) билгеләү һәм уздыру тәртибе, делегатларны сайлау әлеге Устав һәм Район Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**18нче маддә. Гражданнарны сораштыру**

1. Гражданнарны сораштыру Районның бөтен территориясендә яки бер өлешендә, җирле үзидарә дәүләт хезмәтендәге затлар, шулай ук дәүләт власте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре рекомендация характерында була.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукы булган Район халкы катнаша ала.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәге инициативалар буенча үткәрелә:

1) Район Советы, Район Башлыгы – әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары – республика һәм регионара әһәмиятле объектлар өчен Район җирләрен максатчан куллануны үзгәртү буенча карарлар кабул иткәндә халык фикерен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе Район Советының норматив хокук актлары белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карар Район Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында Район Советы карарында күрсәтелә:

1) сораштыруны үткәрү вакыты һәм датасы;

2) сораштыруны үткәрү вакытында тәкъдим ителәчәк сорау (сораулар) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру бите формасы;

5) сораштыруда катнашкан Район халкының минималь саны.

6. Район халкы гражданнарны сораштыру үткәрү турында аны үткәрергә 10 көннән дә ким булмаган көн кала хәбәр ителергә тиеш.

7. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру белән бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләр белән тормышка ашырыла:

1) Район бюджеты акчасы хисабына- Район җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру үткәрелгән очракта;

2) Татарстан Республикасы бюджеты хисабына - Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәрелгән очракта.

8. Сораштыру нәтиҗәләре ул уздырылганнан соң бер ай эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән Районның теләсә кайсы кешесе танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре Районның җирле үзидарә органнары тиешле карарларны кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

**19нчы маддә. Аеруча әһәмиятле булган мәсьәләләрне халык тикшерүе**

1. Муниципаль хокук актлары проектларын чыгару турында карар һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләрне халык тикшерүенә чыгару үз инициативасы буенча Район Советы тарафыннан яки шушы территориядә яшәгән гражданнар таләбе буенча Район Советы билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

2. Муниципаль хокук актлары проекты тексты һәм халык тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча башка материаллараларны халык тикшерүенә чыгару турында карар кабул ителгән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълумат чараларында бастырыла, Район

халкына җибәрелә, халык таныша алырлык урыннарда урнаштырыла, башка юллар белән халыкка җиткерелә.

3. Халык тикшерүенә мәсьәләләрне чыгару белән беррәттән Район Советы тикшерү барышында кергән тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне тикшерү буенча эшне оештыру вакытын һәм тәртибен билгели, билгеләнгән максатлар өчен махсус комиссия төзи.

4. Район Советы аның тарафыннан кертелгән муниципаль хокук актлары проектларын һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерүне тәэмин итә, моның өчен шартлар тудыра.

5. Халык тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр Район Советына җибәрелә.

6. Муниципаль хокук актлары проектлары һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр Район Советы тарафыннан карап тикшерелә.

7. Халык тикшерүе нәтиҗәләре турында халыкка хәбәр ителә.

## 20нче маддә. Җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате

1. Район җирле үзидарә органнарына гражданнар шәхси һәм коллектив мөрәҗәгать итергә хокуклы.

2. Районның һәрбер җирле үзидарә органында бу органнарның компетенциясенә караган сораулар буенча халыкны кабул итү оештырыла, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшерү һәм хәл итү оештырыла.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен тикшерү тәртибе турында” 2нче май, 2006нчы ел, №59-ФЗ Федераль канунында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта каралырга тиеш.

4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен тикшерү тәртибен һәм вакытын бозган өчен җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары Россия Федерациясе кануннарына туры китереп җаваплы булалар.

## 21нче маддә. Районның иҗтимагый (консультатив) советлары

1. Районның җирле үзидарә органнары һәм гражданнарының үзара бәйләнешләрен булдыру өчен, әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча карарлар эшләгәндә һәм тормышка ашырганда халык мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алу максатыннан, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген контрольдә тоту өчен Районның Иҗтимагый советы төзелә.

2. Районның Иҗтимагый советы аның эшчәнлегендә Район халкының, иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның ирекле катнашуы нигезендә барлыкка килә.

3. Районның Иҗтимагый советы барлыкка килү тәртибе, вәкаләтләре, аның утырышларын үткәрү тәртибе һәм карарлар кабул итү, Районның җирле үзидарә органнарының Районның Иҗтимагый советы эшчәнлегенә мәгълумати, консультатив ярдәм итү хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, аны тарату процедурасы, шулай ук аның эшчәнлеге буенча башка мәсьәләләр Район Советы раслаган кагыйдәнамә белән билгеләнә.

4. Башка иҗтимагый (консультатив) советлар Районның җирле үзидарә органнары каршында, аларның карарлары белән яраклаштырып, барлыкка килергә мөмкин.
5. Иҗтимагый (консультатив) советларда эш җәмәгатьчелек тәртибендә башкарыла.

**22нче маддә. Район халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруның башка формалары һәм аны тормышка ашыруда катнашуы**

1. Федераль канунга туры китереп, әлеге Устав белән каралган, җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыру формалары һәм аны тормышка ашыруда катнашуы белән беррәттән гражданнар җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга, Татарстан Республикасы кануннарына каршы килми торган башка формаларын тормышка ашыруда катнаша ала.
2. Район халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруы һәм аны тормышка ашыруда катнашуы законлылык һәм ихтыяри принципларына нигезләнә.
Районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары халыкка Район халкының җирле үзидарәне турыдан – туры тормышка ашыруында һәм аны тормышка ашыруда катнашуында ярдәм итергә тиеш.

## IIIнче бүлек. Район Советы

**23нче маддә. Район Советы- Район җирле үзидарәсенең сайлап куелган органы**

1. Район Советы - җирле үзидарәнең даими гамәлдәге коллегиаль сайлап куелган органы булып тора.
2. Район Советының рәсми исеме – "Югары Ослан муниципаль район Советы".
3. Район Советының вәкаләтлек вакыты-5 ел.
4. Район Советы районда яшәүчеләр белән хисаплашырга һәм контрольле булырга тиеш.
5. Район Советының герблы мөһере һәм үзенең атамалары һәм билгеләнгән үрнәктә Район гербы сурәте белән бланклары бар.
6. Район Советы эшчәнлеген оештыруга тотылган акча Россия Федерациясе чыгымнар классификациясенә туры китереп район бюджетында аерым юл белән карала.

**24нче маддә. Район Советы составы**

1. Район Советы 40 депутаттан тора.
2. Район Советы аның составына Район Советы билгеләгән саннан өчтән ике өлештән ким булмаган депутатларны сайлаганда хокуклы була.

**25нче маддә. Район Советы депутатларын сайлау тәртибе**

1. Район Советы составына вазифалары буенча Район составына кергән авыл башлыклары, күрсәтелгән авылларның сайлап куелган органнарының үз составларыннан сайлап куелган органнар сайлаган һәр авылдан халык санына карамастан бер вәкил исәбеннән депутатлар керә.

Әгәр "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль канунына туры китереп муниципаль территория составына гражданнар җыены белән башкарылган сайлап куелган органнарның вакәләтлеге булган авыллар керсә, андый авыллардан муниципаль район Советына депутатлар сайлау шул авылның уставы белән билгеләнгән вакыт һәм тәртип буенча гражданнар җыены белән башкарыла.

2. Авылның сайлап куелган органы депутатлары арасыныннан сайланган Район Советы депутаты, алдагы чакырылыш органнары вәкаләте вакытыннан алда туктатылган очракта, шул авылның тиешле органнарына яңа чакырылыш беренче утырыш көненнән бер айдан да соңга калмыйча сайланырга тиеш.

3. Авылның сайлап куелган органы депутатлары арасыныннан сайланган Район Советы депутатын сайлау яшерен тавыш бирү һәм күрсәтелгән органның карары белән рәсмиләштерелә.

4. Авылның сайлап куелган органының авыл башлыгын сайлау һәм авылның сайлап куелган органының депутатын Район Советы депутаты итеп сайлау турындагы карары өч көн эчендә Район Советына җибәрелә.

**26нчы маддә. Район Советы депутаты статусы**

1. Район Советы депутаты статусы Россия Федерациясе Конституциясе, федераль кануннар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Район Уставы, Район Советы депутаты статусы турында Кагыйдәнамәгә туры китереп билгеләнә.

2. Район Советы депутаты вәкаләтләре аны авылның сайлап куелган органы депутатлары арасыннан авыл башлыгы яки Район Советы депутаты итеп сайлап куйган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Район Советы эшен башлаган көннән туктатыла.

3. Район Советы депутаты, бу Устав белән билгеләнгән очраклардан кала, азат ителмәгән эшкә таянып депутат эшчәнлеген төп эш урынындагы хезмәт вазифалары белән берләштереп алып бара.

4. Район Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль кануннар белән билгеләнә.

5. Район Советы депутатына үзенең вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен кануннар, бу Устав, Район Советы карарына туры китереп шартлар тудырыла.

6. Район Советы депутаты Район Советы раслаган депутат этикасы Кагыйдәләрен, шул исәптән түбәндәге йөкләмәләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелып торырга һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, оешмаларга, вазифа затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм гражданнарга, аларның туганнарына яки үзләренә кагылышлы мәсъәләләрне чишкәндә, депутат статусын кулланып, йогынты ясарга тиеш түгел;

2) депутат вазифаларын объектив башкаруда шикләнүләр туганда эш – гамәлләреннән тыелып торырга тиеш, шулай ук Район Советы дәрәҗәсенә

яки абруена зыян китерергә сәләтле булган конфликт ситуацияләрне булдырмый калырга тиеш;

3) конфликт ситуацияләре килеп чыгу куркынычы туган очракта, депутат вазифаларын башкаруга комачаулык иткән шәхси кызыксынулар тәэсир итә яки тәэсир итергә мөмкин булган очракта, Район Советына хәбәр итергә һәм аның әлеге конфликт ситуацияләрне булдырмый калдыруны яки җайлауга юнәлтелгән карарларын үтәргә тиеш;

4) Район Советы урнаштырган халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә тиеш;

5) федераль кануннарга туры китереп, конфидинциаль характердагы мәгълуматларга караган мәгълуматларны, Район Советы Депутаты вазифаларын башкарган вакытта депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган үзенә билгеле булган мәгълуматны таратырга һәм шул максатларда кулланырга тиеш түгел;

6) депутат вазифаларын башкару аркасында физик һәм юридик затлардан бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, булышлык, күңел ачулар, яллары, трансполрт чыгымнары өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алмаска тиеш.

7. Вәкаләтләрен өзлексез вәкаләтлеккә таянып тормышка ашырган депутат, Район җирле үзидарәсенең сайланган орган әгъзасы, Район җирле үзидарәсенең сайланган дәүләт хезмәтендәге зат хокукына ия түгел:

1) үзе яки ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек белән шөгыльләнә алмый, шулай ук федераль кануннар белән башка нәрсәләр каралмаган булса, һәм Россия Федерациясе кануннарына, федераль кануннарга туры китереп урнаштырылган тәртиптә, бу оешма белән идарә итү аңа йөкләнмәгән булса, муниципаль хокук актлары билгеләгән, хуҗалык алып баручы субъект белән (билгеле тәртиптә рәсмиләштерелгән торак, торак- төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез мөлкәт һәм профсоюз ширкәте) идарә итүдә катнашырга;

2) укыту, фәнни һәм башка иҗади эш белән шөгыльләүдән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә; ләкин укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эш өчен түләү, Россия Федерациясе кануннарында һәм Россия Федерациясе халыкара килешүе белән башкача каралмаган очракта, чит дәүләт хисабына, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары акчасы хисабына була алмый;

3) Россия Федерациясе кануннары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе белән башка нәрсә каралмаган очракта, Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче чит ил структур бүлекчәләре һәм дәүләтнеке булмаган һәм коммерцияле булмаган органнарына, идарә, попечительләр һәм күзәтүче органнар составына керергә;

4) гражданлык һәм хокукый эшләр яки административ хокук бозулар буенча яклаучы яки вәкил сыйфатында (законлы вәкиллек очракларыннан кала) катнаша алмый.

8. Депутат, җирле үзидарәнең сайлау органы заты, җирле үзидарә органының дәүләт хезмәтендәге заты “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны һәм башка федераль кануннарда билгеләнгән тәртиптә чикләүләр һәм тыюларны сакларга һәм вазифаларын үтәргә тиеш.

**27нче маддә. Район Советы депутатының Район халкы белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Район Советы депутаты Район халкы, шулай ук Район териториясендә урнашкан күмәк хуҗалыклар, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар белән элемтәдә тора.

2. Район Советы депутаты вәкил буларак авыл халкы алдында башкарган эшләре буенча елга бер тапкырдан да ким булмаган хисап тота, аларны Район Советы эшчәнлеге белән даими таныштырып тора, шулай ук айга бер тапкырдан да ким булмаган халыкны кабул итү алып бара.

3. Район Советы депутаты канунда каралган буенча Район халкының законлы хокукларын, иреген һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча, шул исәптән алардан килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карап чыгырга һәм аларның сорауларының вакытында чишелеше буенча дөрес чаралар күрергә тиеш.

**28нче маддә. Яңа сайланган Район Советы эшен оештыру**

1. Яңа сайланган Район Советы беренче утырышына Район уставы белән билгеләнгән срокка Район Советының хокуклы составта сайланган көннән 30 көннән узып китмичә җыела.

2. Сайлаулардан соң Район Башлыгын сайлаганчы Район Советының беренче утырышын Район Советының яше буенча олырак булган депутат ача һәм алып бара.

**29нчы маддә. Район Советы компетенциясе**

1. Район Советы компетенциясенә керә:

1) Район уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) Район территориясендә гомумүтәлешле кагыйдәләр булдыру;

3) Район бюджетын һәм аның үтәлеше турында отчётны раслау;

4) Россия Федерациясенең салымнар һәм җыелган акчалар турындагы канунга туры китереп җирле салымнар һәм җыелган акчалар, аларны түләү буенча ташламалар бирелүне булдыру, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

5) Район үсеше буенча планнар һәм программалар кабул итү, аларның үтәлеше буенча отчёт раслау;

6) Районның чикләрен үзгәртү буенча инициатива белән чыгу;

7) җирле референдумны билгеләү;

8) Район Башлыгын билгеләү, Район Башлыгының отставкага китүе турында карарын кабул итү;

9) Район Башкарма комитеты Җитәкчесен, Финанс-бюджет Палатасы Рәисен, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы Рәисен, Контроль-хисап Палатасы Рәисен билгеләү һәм аларның отставкага китүен кабул итү;

10) районның җирле үзидарә органнары структурасын раслау, районның һәрбер җирле үзидарә органының эчке структурасын һәм штат расписаниесен раслау;

11) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына керү буенча конкурс үткәрү тәртибен билгеләү, конкурс комиссиясе әгъзаларын раслау;

12) Финанс-бюджет Палатасы, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы , Контроль-хисап Палатасы турында Кагыйдәнамәне раслау;

13) Район Сайлау комиссиясе әгъзаларын раслау;

14) Районның чикләрен үзгәртү буенча сорауларны тавышка куюны билгеләү;

15) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру;

16) Районның муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм куллану тәртибен билгеләү, шул исәптән федераль канунга туры китереп аларны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; Район Советы раслауыннан соң яки килешү буенча тартып алынган муниципаль мөлкәт төрләренең исемлеген билгеләү;

17) муниципаль предприятие һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртү һәм юкка чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү, шулай ук федераль канунда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтенә тарифларны кую тәртибен һәм аларны куюны билгеләү;

18) Райнннның муниципальара хезмәттәшлекне оештыруда катнашу тәртибен билгеләү;

19) районныың җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең материаль- техник һәм оештыруны булдыру тәртибен билгеләү;

20) Районның җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлап куелган затларының урындагы мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрен үтәүне тикшерү;

21) гамәлдәге кануннарга туры китереп Районның заем акчаларын куллану, муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чыгару тәртибен билгеләү тәртибен раслау;

22) Районны территориаль планлаштыру документларын раслау, Россия Федерациясе Шәһәртөзү кодексына туры китереп башка шәһәртөзү документларын раслау;

23) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм материаль ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм куллану тәртибен билгеләү;

24) авылларның бюджет җитешлеге дәрәҗәсен тигезләү өчен Район бюджетыннан тиешле акчаның бүлеп бирелү тәртибен һәм шартларын билгеләү;

25) автоном коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар формасында коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карар кабул итү;

26) үзенең массакүләм мәгълумат чараларын оештыру;

27) Район Уставын һәм Район Советы карарларын аңлату;

28) үзенең эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Район Советы Регламентын һәм башка карарларны кабул итү;

29) Район Советы аппараты турында Кагыйдәнамәне раслау;

30) федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннарына буйсынган муниципаль районнарның сайлап куелган органнарына бирелгән башка вәкаләтләре, шулай ук бу Устав тарафыннан Район Советы компетенциясенә буйсынган башка вәкаләтләре.

Район Советы Район Башлыгының, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең аларның эшчәнлеге нәтиҗәләре, Район Башкарма комитеты эшчәнлеге һәм башка Район Башлыгы идарә тармаклары, Районның җирле

үзидарә органнарының, шул исәптән Район Советы күтәргән мәсьәләләрне чишү турында еллык отчётын тыңлый.

2. Район Советы, Район Башлыгы яки аерым депутатлар (депутат төркемнәре) тарафыннан, район бюджеты акчаларының Район Советы, Район Башлыгы һәм депутатларның эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән акчалардан кала, нинди формада булуына карамастан, Район бюджеты акчалары белән идарә итү һәм куллану тыела.

**30нчы маддә. Район Советының эшләү тәртибе**

1. Район Советының эшләү тәртибе бу Устав һәм Район Советы Регламенты белән билгеләнә.

2. Район Советының төп эш формасы булып аның Район компетенциясенә кагылышлы сорауларны чишә торган утырышлары тора.

3. Район Уставы белән Район Советы утырышларының хокуклылыгы билгеләнә. Әгәр Район Советы утырышында сайлап куелган депутатларның 50 процентган кимерәге катнашса, ул хокуклы дип саналмый.

4. Район Советының чираттагы утырышы кирәк булганда, ләкин кимендә өч айга бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш утырышлар Район Башлыгы яки Район Советының билгеләнгән депутатларның кимендә өчтән бер өлеше санынча депутатлар төркеме инициативасы буенча чакырыла.

5. Совет утырышлары Район Башлыгы тарафыннан чакырыла. Район Советы депутатлары һәм чакырылган затлар киләсе утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе белән биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырышка –аны үткәрергә бер көн кала хәбәрдар булырга тиешләр.

6. Район Советы утырышлары ачык һәм белдереп үткәрелә. Район Советының ачык утырышларында Районның теләсә кайсы кешесе катнаша ала.

Регламент белән каралган очракта, Район Советы ябык утырышлар үткәрү турында карар кабул итергә хаклы, һәм анда Район Советы чакырган затлар гына, шулай ук кануннарга туры китереп утырышта катнашырга хокукы булган затлар катнаша ала.

7. Район Советының һәрбер утырышы протоколга теркәлә һәм язып барыла. Җыелыш беркетмәсенә җыелышның датасы, үткәрү урыны, үткәрү вакыты турында мәгълумат, каралачак барлык сораулар саналып чыга һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен күрсәтеп барлык кабул ителгән карарлар теркәлә. Район Советы җыелышы беркетмәсенә Район Башлыгы кул куйганнан соң, аның белән Районның теләсә кайсы кешесе таныша ала.

8. Район Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Район Советы депутаты тавыш бирүгә хокукын үзе башкара. Район Советында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм ябык була ала. Һәр төр тавыш бирүне куллану бу Устав, Район Советы Регламенты белән билгеләнә.

**31нче маддә. Район Советы эшчәнлеген оештыру**

1. Район Советы эшчәнлеген оештыруны Район Башлыгы башкара.

2. Район Советы Регламентына туры китереп Район Советы компетенциясенә караган сорауларны алдан карау һәм әзерләү өчен Район Башлыгыннан һәм аның урынбасарыннан кала депутатлардан Район Советы

эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комитет оештырыла, шулай ук даими һәи вакытлы комиссияләр оештырылырга мөмкин.

3. Муниципаль программаларны, Район Советы карарлары проектларын әзерләү өчен, Районга кагылышлы әһәмиятле сорауларны тикшерү өчен, Район Советы каршында аның карары буенча депутатлар, Район Башкарма комитеты вәкилләре, иҗтимагый оешмалар, организацияләр һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм Район халкы составында, партия фракцияләре, эшче, эксперт һәм башка киңәш итүче төркемнәр оеша ала.

4. Район Советының оештыру, хокук, мәгълумати, матераль- техник һәм башка эшчәнлеген тәэмин итүне Район Советы аппараты тәэмин итә.

## 32нче маддә. Район Советының контроль функцияләрне тормышка ашыруы

1. Район Советы Район территориясендә бу Уставның кагыйдәнамәләре үтәлешен, Район Советы кабул иткән норматив актлар, Район бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш акчаларны куллану, Районның үсеш программаларын, Район Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка органнары эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыра.

2. Район җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары кануннарны, бу Уставны һәм башка муниципль хокук актларын бозган очракта, Район Советы, Район Башлыгы карары нигезендә билгеләнгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләр оешырга мөмкин.

3. Кануннарга яраклаштырып Район Советы, Район Башлыгы карары нигезендә Район бюджеты акчаларының максатчан кулланылышын тикшерү (ревизия), муниципаль мөлкәтнең нәтиҗәле кулланылышын тикшерә ала, шулай ук Район Башкарма комитетының башка финанс-хуҗалык мәсьәләләрен тикшерү үткәрә ала. Тикшерү (ревизия) үткәрергә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарыннан белгечләр, бәйсез аудиторлар җәлеп ителә ала.

4. Район Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазифаи затлар, канун белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, Район Советы, аның контроль коиссияләре, Район Советы депутаты мөрәҗәгате буенча соратып алынган Район Советын җитәкләү белән бәйле мәгълуматны бирергә тиеш, ә кануннарны, муниципаль хокук актларын бозу очраклары ачыкланса, җитешсезлекләрне бетерү өчен һәм гаепплеләрне җавапка тарту буенча кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Район Советы, контроль функцияләрен тормышка ашырганда, Район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкару-күрсәтмә бирү эшчәнлегенә катнашырга хокуклы түгел.

## 33нче маддә. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) район Советы үз-үзен тарату турында карар кабул иткән очракта;

2) канунда каралган дәлилләр буенча һәм билгеләнгән тәртиптә Район Советы таратылса;
3) Татарстан Республикасы Югары судының Район Советы депутатлар составының хокуксыз булуы турында карары көченә кергәч, шул исәптән депутатлар үзләренең вәкаләтләрен өстеннән төшерсә;
4) федераль кануннарга туры китереп тормышка ашырылган, Районны үзгәртеп кору булган, шулай ук Районны бетергән очракта;
5) Район чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә;
2. Район Советы вәкаләтенең вакытыннан алда туктатылуы аның депутатлар вәкаләтләренең туктатылуына сәбәп була.
3. Район Советы вәкаләте вакытыннан алда туктатылган очракта авылларның сайлап куелган органнары бер ай эчендә Район Советы составына башка депутатларны сайлап куерга тиеш.

**34нче маддә. Район Советының үз-үзен тарату турында карар кабул итү тәртибе**

1. Район Советының үз-үзен тарату турында карары Район Башлыгы яки Район Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган депутатлар төркеме инициативасы буенча кабул ителә ала.
2. Үз-үзен тарату турында карар кабул итү инициативасы күрсәтелә алмый:
1) Район Советын сайланудан соң беренче елы эчендә;
2) Район бюджеты кабул ителгән һәм аның үтәлеше турында отчёт расланган вакытта;
3) яңа Район Башлыгын сайлаганчы Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта.
3. Район Советының үз-үзен тарату турында язмача тәкъдиме үз-үзен тарату сәбәпләрен күрсәтергә тиеш, шулай ук аңа үз-үзен тарату сәбәпләрен дәлилләгән материаллар куелырга тиеш.
4. Үз-үзен тарату турында сорауны алдан карап чыгу буенча Район Советы депутатлары саныннан комиссия төзелә. Район Советы яки Район Башлыгы карары буенча Район Советының үз-үзен тарату турында мәсьәләсе халык тыңлауларына куелырга мөмкин.
5. Район Советының үз-үзен тарату турында мәсьәләне карау дәвамлылыгы Район Советы депутатлары һәм Район халкы тарафыннан үз-үзен тарату инициативасының барлык шартлары һәм җирлекләрен һәр яклап һәм объектив тикшерү мөмкинлегенә гарантия бирергә тиеш.Үз-үзен тарату турында карар үз-үзен тарату инициативасы күрсәтелгән көннән алып ике ай узганнан соң кабул ителә ала.
6. Район Советының үз-үзен тарату турында карары яшерен тавыш бирү юлы белән Район Советы депутатларының билгеләнгән саннарның өчтән ике өлеш тавыш белән кабул ителә.
7. Район Советы тарафыннан үз-үзен тарату турында тәкъдиме кире кагылса, кабат үз-үзен тарату турында инициатива үз-үзен тарату мәсьәләсе буенча тавыш биргән көннән алып бер елдан да иртәрәк була алмый.

**35нче маддә. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:
1) үлгән очракта;
2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;
3) суд тарафыннан хезмәткә яраксыз яки чикле эшкә яраклы дип табылса;
4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;
5) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;
6) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;
7) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы -чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины җирле үзидарә органнарына сайлана ала;
8) авылның сайлап куелган депутаты буларак, сайлаучылар тарафыннан азат ителә. Район Советы депутатын, шул исәптән Район Башлыгын азат итүгә нигез булып депутатның суд тәртибендә расланган, сайлаучыларында шик тудырган, Район Башлыгы вазифаларын һәм депутат вазифаларын тиешенчә башкармаган законсыз карарлары һәм гамәлләре нигез булып тора, депутат статусына туры килмәгән гамәлләр кылса, шулай ук Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, норматив- хокук актларын, башка муниципаль хокук актларны, бу Уставны бозса;
9) Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса;
10) хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә алынса;
11) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында ”Федераль канунда билгеләнгән башка очракларда.
2. Район Советы депутатының вәкаләтләрен туктату турындагы карары депутат вәкаләтләре туктатылган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу очрак район Советы сессияләре арасында булса, өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.
3. Бу авылның сайлап куелган органнарыннан депутатлар арасыннан булган Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, әлеге орган бер ай эчендә Район Советы составына башка депутатны сайларга тиеш.

## IV нче бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫ

### 36нчы маддә. Район Башлыгы – Районның югары вәкаләтле шәхесе

1. Район Башлыгы Районның югары вәкаләтле шәхесе булып тора.
2. Район Башлыгы Район Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара.
3. Район Башлыгының рәсми исеме- Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы.

### 37нче маддә. Район Башлыгын сайлау тәртибе

1. Район Башлыгы яңа сайланган Район Советының беренче утырышында Район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән Район Советы вәкаләте вакытына сайлана.

2. Район Башлыгын сайлау Район Советы депутатлары күрсәткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән Район составына кергән авылларның сайлап куелган органнары, Район халкы, иҗтимагый оешмалар, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә сайлана.

3. Саланганнан соң Район Башлыгы түбәндәгечә ант бирә:
“Миңа йөкләнгән Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының зур бурычларын тормышка ашырганда Россия Федерациясе кануннарын һәм Конституциясен, Татарстан Республикасы кануннарын һәм Конституциясен, Югары Ослан муниципаль районы Уставын үтәргә, Район кешеләренең мул тормышын тәэмин итү өчен бөтен белемемне һәм көчемне куярга, кеше һәм гражданин хокукларын сакларга ант итәм”.

**38нче маддә. Район Башлыгының статусы**

1. Район Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Район Башлыгы, федераль канун белән билгеләнгән Район Башлыгы статусы белән туры килми торган вазифаны алмаштыра алмый, шулай ук эшмәкәрлек, шулай ук, укыту, фәнни һәм башка иҗади эштән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокукы юк.

3. Район Башлыгы үзенең эшчәнлегендә, бу Устав һәм федераль канунга туры китереп, Район Советына һәм Районда яшәүче халык контрольлегендә һәм отчётында .

4. Район Башлыгы үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Район Советына еллык отчётларын тәкъдим итә.

**39нчы маддә. Район Башлыгының вәкаләтләре**

Район Башлыгы:

1) башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, дәүләт хаккимияте органнары белән, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәттә Район исеменнән эш алып бара, Район исеменнән ышаныч язуыннан башка эш йөртә;

2) Район Советы эшен оештыра, Район Советы утырышларын җыя һәм аларда рәислек итә;

3) бу Устав белән билгеләнгән тәртиптә, Район Советы кабул иткән хокук актларына кул куя һәм халыкка белдерә, шулай ук Район Советы утырышлары беркетмәләренә кул куя;

4) үзенең вәкаләтләре кысаларында Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокук актлары чыгара;

5) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт төзи;

6) Район Советы эшчәнлегендә җәмәгатьчелек фикерен исәпләү һәм ачыклык булдыру буенча чаралар күрә;

7) халыкны кабул итә, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) Район Советы утырышларының беркетмәләренә кул куя;

9) Район Советы аппараты эшчәнлеге белән җитәкчелекне тормышка ашыра;

10) Район Советы контроль вәкаләтләренең тормышка ашырылуын килештерә;

11) Район бюджетында каралганча, Район Советы эшчәнлеген тәэмин итү һәм тотуга акчаларны бүлүче булып тора;

12) канунга һәм бу Уставка туры китереп, халыкның үз ирке белән кабул ителгән карарларын тормышка ашыру буенча Район Советының хокук актларын кабул итүне оештыра;

13) Районның җирле үзидарә органнарының Татарстан территориясендә эшләп килүче башкарма хакимият федераль органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнешен булдыра;

14) Район исеменнән дәүләт хакимияте органнары белән, башка муниципаль берәмлекләр белән икътисад һәм иҗтимагый- мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүнамәләр һәм килешүләр төзи, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнеш турында һәм гамәлләрне килештерү турында килешүнамәләр һәм килешүләр төзи;

15) җирле үзидарә органнарыны тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары кануннары һәм федераль кануннары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләре һәм әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруны булдыра;

16) муниципаль район башлыкларының идарә итүе турында федераль кануннар белән, Татарстан Республикасы кануннары белән бирелгән башка вәкаләтлекләрне, шулай ук бу Устав, Район Башлыгы компетенциясенә караган Район Советы карарлары белән бирелгән башка вәкаләтлекләрне тормышка ашыра.

Район Башлыгы “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны һәм башка федераль кануннарда билгеләнгән тәртиптә чикләүләр һәм тыюларны сакларга һәм вазифаларын үтәргә тиеш.

**40нчы маддә. Район Башлыгы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы**

1. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз ризалагы белән отставкага китсә;

3) федераль кануннарга яраклаштрып отставкага җибәрелсә;

4) гамәлдәге кануннарга туры китереп вазифасыннан баш тартса;

5) суд карары нигезендә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип табылса;

6) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;

7) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;

8) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы -чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил

гражданины Районның җирле үзидарә органнарына сайлана ала, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртылып алынса;

11) сәламәтлеге буенча Район Башлыгы вәкаләтләрен башкара алмауы турында суд тәртибендә билгеләнсә;

12) федераль кануннарга туры китереп тормышка ашырылган, Районны үзгәртеп кору булган, шулай ук Районны бетергән очракта;

13) Район чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә.

Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда Район Башлыгы, аның хатыны һәм балалары “Россия территориясеннән чиктә булган чит ил банкларында акча саклау һәм счёт ачу аерым категория затларга тыелуы турында”Федераль канунында билгеләнгән чикләүләрне сакламаган очракта, Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалткан вакытта туктатыла.

2. Бу маддәнең 1нче пунктында күрсәтелгән дәлилләр буенча, Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Район Башлыгын сайлау Район Советының якындагы утырышында башкарыла.

3. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда Район Советы вәкаләтләре тәмамлануга кимендә алты ай кала туктатылган очракта, яңа Район Башлыгын сайлау Район Советы карары буенча үткәрелмәскә мөмкин.

4. Район Советы тарафыннан сайланган Район Башлыгы Район Советының аны отставкага җибәрү турында карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, суд тәртибендә әлеге карарга шикаять бирә ала, Район Советы Район Башлыгын суд карары көченә кергәнче аны сайлау турындагы карарны кабул итә алмый.

### 41нче маддә. Район Башлыгын отставкага җибәрү

1. Федераль кануннарга туры китереп Район Советы Район Советы депутатлары яки Татарстан Республикасы хезмәтендәге зат инициативасы буенча Район башлыгын отставкага җибәрә ала.

2. Район башлыгын отставкага җибәрү өчен җирлек булып түбәндәгеләр тора:

1) Федераль канунда каралган буенча Район башлыгының карарлары, гамәлләре (гамьсезлекләре) күңелсез нәтиҗәләр китереп чыгарса (китереп чыгарсалар);

2) өч ай һәм аннан да күбрәк вакыт эчендә Район Уставы, федераль кануннарда каралганча, үзенең вәкаләтләрен тормышка ашыруда урындагы мәсьәләләрне чишү буенча вазифаларын башкармаса, яки Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән каралган җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруны үтәмәсә;

3) Район Башлыгының эшчәнлегенә Район Советы тарафыннан Район Советы каршында аның еллык отчётына ике тапкыр рәттән канәгатьләндерерлек бәя бирелмәсә.

4) “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны һәм башка федераль кануннарда билгеләнгән тәртиптә чикләүләр һәм тыюларны сакламаган һәм вазифаларын үтәмәгән очракта;

5) Район Башлыгы, районның Башкарма комитеты җитәкчесе һәм башка органнар һәм оешмалар тарафыннан кеше хокуклары һәм иреге, дине һәм башка хокукларын чикләү булып, милләтара (этникара) һәм конфессиональ конфликтлар китереп чыгарса, дәүләт гарантияләрен бозу булса;

3. Район Советы депутатларының өчтән береннән дә ким булмаган төркеме тәкъдим иткән Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасы мөрәҗәгать формасында язылa һәм Район Советы карауына кертелә. Әлеге муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында мөрәҗәгать Район Советының карар проекты белән бергә кертелә. Әлеге инициативаны тәкъдим итү турында Район Советының әлеге мөрәҗәгате тәкъдим ителгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча Район башлыгы һәм Татарстан Республикасының югары дәүләт хезмәтендәге затка җитекерелә.

4. Район Советы депутатларының Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасын карау Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге шәхеснең фикерен исәпкә алып тормышка ашырыла.

5. Район Советы депутатларының Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасын караган вакытта федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәләләр карала, яки Федераль канунда каралган буенча Район башлыгының карарлары, гамәлләре (гамьсезлекләре) күңелсез нәтиҗәләр китереп чыгарса (китереп чыгарсалар), Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге зат килешүе буенча гына кабул ителә ала.

6. Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге затның Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасы мөрәҗәгать итеп язылa һәм Район Советы карарының туры килгән проекты белән бергә Район Советы карауына кертелә. Бу инициативаны тәкъдим итү турында Район Советы күрсәтелгән мөрәҗәгатьне керткәч бер көннән соңга калмыйча Район башлыгына хәбәр итергә тиеш.

7. Район Советы депутатларының яки Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге затның Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасын карау әлеге мөрәҗәгать кертелгән көннән соң бер ай эчендә каралырга тиеш.

8. Район Советы депутатларының Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары өчен Район Советы депутатлары арасыннан икедән өч өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

9. Район Советы депутатларының Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы карарына Район Советы утырышында рәислек иткән депутат кул куя.

10. Район башлыгы, төп тавыш бирү хокукы белән Район Советы составына кергән һәм аның рәисе вазифаларын үтәгән очракта, аны отставкага җибәрү турындагы мәсьәләне караганда Район Советы утырышында катнаша икән, бу утырыш Район Советы тарафыннан билгеләнгән Район Советы депутаты рәислегендә уза.

11. Район Советы тарафыннан Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы карар каралганда һәм кабул ителгәндә тәэмин ителергә тиеш:

1) тиешле утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында белдерү кәгазе алу, шулай ук Район Советы депутатларының һәм Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге шәхеснең мөрәҗәгате һәм аны отставкага җибәрү турындагы Район Советы карары проекты белән танышу;

2) Район Советы депутатларына, аны отставкага җибәрү өчен нигез итеп күрсәтелгән шартларны аңлату мөмкинчелеге бирү.

12. Район Советы башлыгы Район Советының аны отставкага җибәрү турындагы карары белән килешмәсә, үзенең төп фикерен язма рәвештә аңатып бирергә хокуклы.

13. Район Советы тарафыннан Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы карар аны кабул иткәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла. Район Советы башлыгы Район Советының аны отставкага җибәрү турындагы карарына язма рәвештә үзенең мөһим фикерен җиткерсә, ул Район Советы карары белән бер вакытта басылып чыгарга тиеш.

14. Район Советы депутатларының яки Татарстан Республикасы югары дәүләт хезмәтендәге шәхеснең Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасы кире кайтарылса, Район Советының Район Башлыгын отставкага җибәрү турындагы мәсьәләне икенче тапкыр каралышка әлеге мәсьәлә каралган Район Советы утырышы узганнан соң ике айдан да иртәрәк булмаган вакытта куелырга тиеш .

**42нче маддә. Район Башлыгы Ярдәмчесе**

1. Район Башлыгы тәкъдиме буенча Район Советы тарафыннан депутатлар арасыннан Район Башлыгы ярдәмчесе – Район Советы Рәисе ярдәмчесе сайлана.

2. Район Советы депутаты Район Башлыгы ярдәмчесе булып, аны сайлау өчен Район Советы депутатларының яртыдан артык өлеше тавыш биргән булса, сайланган дип санала.

3. Район Башлыгы ярдәмчесе -Район Советы Рәисе ярдәмчесе, Район Советы Регламенты билгеләгән вазифаларны бүлү белән туры китергән функцияләрне, Район Башлыгы йөкләмәләрен башкара, ә ул вакытлыча булмаган очракта (авыру яки ялы сәбәпле) яки ул үз вазифаларын башкара алмаган очракта яки вакытыннан алда вәкаләтләре туктатылганда, Район Башлыгы вазифаларын башкара.

4. Район Башлыгы ярдәмчесе -Район Советы Рәисе ярдәмчесе үзенең вәкаләтләрен даими нигездә тормышка ашыра.

5. Район Башлыгы ярдәмчесе -Район Советы Рәисе ярдәмчесе вәкаләтләре вакытыннан алда бу Уставның 40нчы маддәсендә каралган нигездә вакытыннан алда туктатыла.

6. Район Башлыгы ярдәмчесе -Район Советы Рәисе ярдәмчесе Район Башлыгы инициативасы буенча кабул ителгән Район Советы карары белән яки Район Советы депутатлары арасыннан өчтән бер өлешеннән ким булмаган төркемнең таләбе буенча теләсә кайсы вакытта вазифасыннан чакыртып алына ала. Район Башлыгы ярдәмчесен чакыртып алу турында

карар Район Советы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

### Vнче бүлек. Район Башкарма комитеты

#### 43нче маддә. Район Башкарма комитеты-Район җирле үзидарәсенең башкаручы - җитәкчелек итүче органы

1. Район Башкарма комитеты-Район җирле үзидарәсенең башкаручы-җитәкчелек итүче органы булып тора.
2. Район Башкарма комитетының рәсми исеме – “Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты”.
3. Район Башкарма комитеты Район Советы белән хисаплашырга һәм контрольле булырга тиеш.
4. Район Башкарма комитетның герблы мөһере һәм үзенең атамалары һәм билгеләнгән үрнәктә Район гербы сурәте белән бланклары бар.
5. Район Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыруга тотылган акча Россия Федерациясе чыгымнар классификациясенә туры китереп район бюджетында аерым юл белән карала.

#### 44нче маддә. Район Башкарма комитеты структурасы

1. Район Башкарма комитеты структурасы Район Советы тарафыннан Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тәкъдим итүе буенча раслана.
2. Район Башкарма комитеты структурасына Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасарлары, Башкарма комитетның өлкә (функциональ) һәм территориаль органнары керә.
3. Район Башкарма комитеты органнары Район Советы тарафыннан расланган кагыйдәнамәләр нигезендә эш итә.
4. Район Башкарма комитеты эшчәнлегенә әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча килешенеп чишүдә ярдәм итү өчен, Район Башкарма комитеты каршында Район Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән координацион, эксперт һәм башка киңәшләшү (консультатив) орган оешырга мөмкин. Бу органнар Район Башкарма комитеты структурасына кермиләр. Аларда эш ихтыяри башкарыла.

#### 45нче маддә. Район Башкарма комитеты вәкаләтләре

Башкарма комитет:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм хисап өлкәсендә:

- Район бюджеты проектын, Районның иҗтимагый-икътисад үсешенең комплекслы программаларын һәм план проектларын эшләүне тәэмин итә;
- Район бюджеты, Районның иҗтимагый-икътисад үсешенең комплекслы программалары һәм план проектлары үтәлешен оештыра;
- Район бюджеты, Районның иҗтимагый-икътисад үсешенең комплекслы программалары һәм план проектлары үтәлеше турында отчёт әзерләүне тәэмин итә;
- Районның иҗтимагый-икътисад өлкәсенең торышын характерлаучы статистик күрсәткечләрне туплауны оештыра;

- авылларның бюджет белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен Район бюджеты хисабына тигезләү.

2) Район территориясендә Район Советы билгеләгән тәртиптә үзенең вәкаләтләре кысаларында муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә, предприятие, учреждение һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- Районның муниципаль милкендә булган муниципаль мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, куллану, идарә итү һәм арендалау буенча мәсьәләләрне чишә;

- Район Советы карары билгеләгән очракта, Район Советы раслауына (килешүенә) милекне тартып алу турында, шул исәптән аны приватизацияләү турында тәкъдимнәрен әзерли һәм кертә ала ;

- муниципаль предприятие һәм учреждениеләр оештыра, аларның эшчәнлеге максатын, шартларын һәм тәртибен билгели, муниципаль учреждениеләрне финанслауны тәэмин итә, муниципаль предприятие һәм учреждениеләрне үзгәртеп кору һәм юкка чыгару мәсьәләләрен хәл итә, аларның җитәкчеләрен контракт нигезендә билгели һәм вазифаларыннан азат итә;

- муниципаль милектә булмаган предприятие һәм оешмалар белән Районның иҗтимагый-икътисад үсешендә хезмәттәшлек турында килешү төзи; Район территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формаларын булдыруга булышлык итә;

- муниципаль заказларны формалаштыра, урнаштыра, муниципаль заказларның үтәлешен тормышка ашыра, бу эшләргә каралган Районның үзенең материал һәм финанс чараларын кулланып Район кирәк-яраклары өчен эшләргә заказ бирүче була;

3) территориаль планлаштыру, җирне һәм башка табигать ресурсларын куллану, әйләнә-тирә мохитны саклау өлкәсендә:

- Район Советы раслауына Районны территориаль планлаштыру документлары проектларын, башка төзелеш документациясен әзерли һәм кертә һәм тормышка ашыруны тәэмин итә;

- Район территориясендә тормышка ашырыла торган төзелеш эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълумат системасын кертүне тормышка ашыра;

- Районның муниципаль милкендә булган җирләрне рациональ куллану һәм саклауны планлаштыру һәм оештыруны тормышка ашыра;

- Район территориясендә урнашкан җирләрне, канунда билгеләнгән тәртиптә, бирә, шул исәптән сатып алу юлы белән тартып ала;

- халыкка экологик хәл турында мәгълумат бирә, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең әйләнә-тирә мөхитка зыян китерүче табигатьтән файдалану турында кануннарны боза торган гамәлләре турында тиешле органнарга хәбәр итә;

- әйләнә-тирә мохитны саклау буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра;

- көнкүреш һәм сәнәгый калдыкларны юкка чыгару һәм эшкәртүне оештыра;

- Район территориясендә әһәмиятле булган дәвалау- савыктыру урыннарын һәм курортларны үстерүне тормышка ашыра һәм саклауны тәэмин итүне булдыра;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- Район территориясендә торак төзелеше өчен уңайлыклар тудыруны тәэмин итә;

- федераль һәм республика юллары, күперләре һәм башка транспорт инженерлык корылмаларыннан кала, Район чигендә торак пунктлар чигеннән тыш гомуми кулланылышта булган торак пунктлар арасындагы юлларны, күперләрне һәм башка транспорт инженерлык корылмаларын төзи һәм карап тора;

- муниципаль транспорт оешмаларын булдыру юлы белән, яки килешү буенча шәхси һәм башка транспорт оешмаларын транспорт хезмәте күрсәтергә җәлеп итү юлы белән халыкка транспорт уңайлыкларын булдыру өчен һәм муниципаль район чикләрендә җирлекләр арасында транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра;

- Район чикләрендә торак пунктлар арасында халыкка хезмәт күрсәтүче җәмәгать транспорты тукталышы урыннарын, маршрутын һәм хәрәкәт итү графигын раслый һәм килештерә;

- Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш, җәмәгать транспорты тукталышы урыннарын төзекләндерүне тәэмин итә;

- җирлекләрне элемтә хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

5) торак- коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- Район чикләрендәге торак пунктларда электр-, җылылык- һәм газ белән тәэмин итүне оештыра;

- Район составына кергән җирлекләрдә элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә шартлар тудыра;

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыра (китапханә коллекторы хезмәтен тәэмин итә);

- җирлекара күмү урыннарын карап тора, ритуаль хезмәтләрне оештыра;

6) мәгариф һәм сәламәтлек өлкәсендә:

- төп белем бирү программалары буенча һәркемгә бушлай башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыра (Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары вәкаләтләренә караган белем бирү процессын финанслау буенча вәкаләтеннән кала );

- Район территориясендә бушлай өстәмә белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирүне оештыра, шулай ук каникуллар вакытында балаларның ялын оештыра;

- Район территориясендә (санитар-авиациядән кала) ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны тәэмин итә, амбулатор- шифаханәләр һәм хастаханәләрдә беренчел медик - санитар ярдәме күрсәтүгә шартлар булдыра, йөкле хатыннарга йөклелек вакытында, бала тапканда һәм бала тапканнан соң медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны тәэмин итә;

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш чаралардан саклау өлкәсендә:

- Район территориясендә кануннарның, дәүләт власте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының актларын саклауны, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында дәүләт власте органнарының һәм дәүләт хезмәтендәге затларның,

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җирле үзидарә хокукларын бозган актларына шикаять бирә;

- федераль кануннарга туры китереп муниципаль полиция тарафыннан җәмәгать тәртибен саклауны оештыра;

- Район чикләрендә гадәттән тыш чараларны кисәтү һәм булдырмый калуда катнаша;

- территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар оештыру һәм тормышка ашыру, муниципаль район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чараларны оештыруны тәэмин итә, гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җирле финанс һәм материал ресурсларны булдыруны тәэмин итә;

- үзенең вәкаләтләре кысаларында билгеләнгән тәртиптә халыкка гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуы куркынычы турында үз вакытында хәбәр итә;

- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итә, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны тормышка ашыра;

- опека һәм тәрбиячелек буенча эшчәнлекне тормышка ашыра;

- Районны үзгәртеп кору һәм чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү, җирле референдумны әзерләү һәм уздыруны оештыру һәм материаль-техник тәэмин итүне тормышка ашыра;

8) Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән Район җирле үзидрә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән Район җирле үзидрә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үти;

- дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен бирелгән материаль һәм финанс чараларын тиешле куллануны тәэмин итә һәм хисап алып бара;

- Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән туры китереп билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру турында хисап тапшыра;

- Район Советы карары белән туры китереп тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәүне тормышка ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары карамагында булган материаль ресурсларны һәм финанс чараларын өстәмә куллануны тәэмин итә;

- Район Советы тарафыннан кабул ителгән әлеге вәкаләтләрне үтәүгә хокукны тормышка ашыру турында карарны кабул иткән очракта, Районның җирле үзидарә органнары федераль кануннар белән туры китереп аларга тапшырылмаган вәкаләтләрне тормышка ашыруда катнаша;

9) башка вәкаләтләр:

- муниципаль архивны, җирлекләрнең архив фондын саклауны кертеп, оештыра һәм карап тора;

- федераль кануннар белән туры китереп үзенең вәкаләтләре кысаларында халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешләрне тормышка ашыра;

- Район Советы, Район Башлыгы яки Районның башка җирле үзидарә органнары компетенцияләренә караган кануннар, әлеге Уставтан кала, Район өчен әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча башка вәкаләтләрне башкара.

**46нчы маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе укыту, фәнни һәм башка иҗади эш белән шөгыльләүдән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хаклы түгел; ләкин укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эш өчен түләү, Россия Федерациясе кануннарында һәм Россия Федерациясе халыкара килешүе белән башкача каралмаган очракта, чит дәүләт хисабына, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары акчасы хисабына була алмый. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе Россия Федерациясе кануннары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе белән башка нәрсә каралмаган очракта, Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче чит ил структур бүлекчәләре һәм дәүләтнеке булмаган һәм коммерцияле булмаган органнарына, идарә, попечительләр һәм күзәтүче органнар составына керергә хакы юк.

**47нче маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү тәртибе**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.
2. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе өчен контракт шартлары Район Советы тарафыннан раслана. Федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары тарафыннан Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган очракта, Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнгән шартлар контрактка мәҗбүри рәвештә кертелә.
3. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына кандилатлар булырга тиеш:
- “дәүләт һәм муниципаль идарә итү” белгечлеге буенча югары профессиональ белем яки муниципаль башка югары профессиональ белемле;
- муниципаль хезмәтнең вазифаи хезмәт төркеменә туры килгән яки аңа тигезләшкән дәүләт граждан хезмәтенең муниципаль вазифаларында ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы, яки белгечлек буенча биш елдан да ким булмаган стаж;
- оешма җитәкчесе яки җитәкче ярдәмчесе вазифасында идарә итү тәҗрибәсе, яки дәүләт органнарында, яки җирле үзидарә органнарында, яки аларның структур бүлекчәләрендә биш елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе;
- Район Советы карары билгеләгән күләмдә Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын башкару өчен кирәкле эшлеклелек сыйфатлары һәм осталыгы.

4. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләүгә конкурс әлеге Устав һәм Район Советы карары билгеләгән тәртиптә үткәрелә.
5. Конкурс шартлары, аны үткәрү көне, вакыты, урыны, контракт проекты массакүләм мәгълумат чараларында конкурс үткәрелгәннән соң 20 көннән дә соңга калмыйча бастырылып чыгарыла.
6. Конкурсны уздыру өчен комиссия төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны Район Советы тарафыннан раслана.

7. Муниципаль районда конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы Район Советы тарафыннан, ә калган яртысы – Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

8. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына шәхес конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан билгеләнә.

9. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт Район Башлыгы тарафыннан төзелә.

**48нче маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакыты**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт шәхесне Районның Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасына билгеләү турында карар кабул иткән Район Советы вәкаләтлеге вакытына (яңа чакырылыш Район Советы эш көне башланганчы) кадәр, ике елдан да ким булмаган вакытка төзелә.

2. Район Советы вәкаләтләре вакыты чыккач, яңа Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләгәнче, Районның Башкарма комитет Җитәкчесе каралган тәртиптә үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.

**49нчы маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре**

Район Башкарма комитеты Җитәкчесе:

1) Район Башкарма комитеты эшчәнлеге белән бер генә кеше идарәсе принципларында идарә итә һәм Район Башкарма комитеты компетенциясенә кергән вәкаләтләрне үтәү өчен шәхси җаваплылык алып бара;

2) Район Башкарма комитетын Район Советы, Район Башлыгы, Районның башка җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль берәмлекләре, дәүләт власте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән бәйләнештә тәкъдим итә;

3) Район Советы карауына районның бюджет проектын һәм аның үтәлеше турында хисапны тәкъдим итә;

4) Районның комплексны иҗтимагый-икътисадый үсеш планы проектын һәм программасын Район Советы карауына тәкъдим итә;

5) Район Башкарма комитеты структурасы проектын Район Советы раслауына кертә, районның муниципаль оешмаларының штат расписаниесен һәм төзелешен раслый;

6) Район Башлыгы белән килештереп Район Башкарма комитеты ярдәмчеләрен билгели һәм вазифаларыннан азат итә, алар арасында вазифаларны бүлә, Район Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка эшчеләрне вазифаларына билгели һәм вазифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата мактау чараларын һәм дисциплина җаваплылыгын куллана;

7) үзенең вәкаләтләре кысаларында расланган бюджетка туры китереп Район акчасы белән идарә итә;

8) Район Башкарма комитеты тарафыннан  Федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән Районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыра һәм (яки) тормышка ашыруны тәэмин итә;

9) Район Башкарма комитеты компетенциясенә караган әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча хокук актлары чыгара, шулай ук Район Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокук актлары чыгара;

10) Район Советы контрольлегендә һәм отчётында, Район Советына үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча һәм Башкарма комитет эшчәнлеге буенча еллык хисап тапшыра, шул исәптән Район Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне чишү буенча ;

11) Район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими мәгълумат тапшырып тора, Район Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга бер тапкырдан да ким булмаган гражданнарны шәхси кабул итүне оештыра,  гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карап тикшерә һәм алар буенча карарлар кабул итә;

12) дәүләт һәм башка органнарда Район мәнфәгатьләрен яклау чараларын күрә, Район Башкарма комитеты исеменнән судка гаризалар бирә, ышанычнамәләр бирә;

13) Район Советы раслауына Район Башкарма комитеты органнары турында кагыйдәнамәләр проектларын тәкъдим итә;

14) муниципаль оешмаларының җитәкчеләрен вазифаларына билгели һәм вазифаларыннан азат итә;

15) канунга, әлеге Уставка, Район Советы карарларына һәм төзелгән контрактка туры китереп башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

**50нче маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда  туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз ризалагы белән отставкага китсә;

3) әлеге маддәнең 2нче пунктына туры китереп контракт өзелгән очракта;

4) гамәлдәге кануннарга туры китереп вазифасыннан баш тартса;

5) суд карары нигезендә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип табылса;

6) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип  яки үлгән дип табылса;

7) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;

8) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы -чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины Районның җирле үзидарә органнарына сайлана ала, чит дәүләт гражданлыгын  яки торырга рөхсәт алса;

10)  хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә алынса;

11) федераль кануннарга туры китереп тормышка ашырылган, Районны үзгәртеп кору булган, шулай ук Районны бетергән очракта;

12) Район чикләрен үзгәрү нәтиҗәсендә булган очракта, сайлаучыларның саны 25 проценттан артып китсә.

2. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча яки суд тәртибендә гариза нигезендә туктатыла:

1) контракт шартларының әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә кагылышлы өлешен бозу аркасында, шулай ук Уставның 45нче маддәсендә билгеләнгән чикләүләрне сакламаган очракта, Район Советының һәм Район Башлыгының;

2) контракт шартларының Федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән Районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга кагылышлы өлешен бозу аркасында, шулай ук Уставның 45нче маддәсендә билгеләнгән чикләүләрне сакламаган очракта -Татарстан Президентының;

3) Районның җирле үзидарә органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары тарафыннан контракт шартларын бозу аркасында - Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең.

## VIнчы бүлек. Район Советының, Район Башлыгының һәм Район Башкарма комитетының үзара мөнәсәбәтләре

### 51нче маддә. Район Советының, Район Башлыгының һәм Район Башкарма комитетының үзара мөнәсәбәтләренең нигезе

1. Бу Кагыйдәнамәдә билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү белән туры китереп, Район Советы, Район Башлыгы һәм Район Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль рәвештә башкара.

2. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты кануннарда, бу Устав белән билгеләнгән формада Районның икътисади һәм иҗтимагый үсеше процессы белән нәтиҗәле идарә итү максатыннан һәм аның халкы ихтыяҗларыннан чыгып үзара бәйләнештә булырга тиеш.

3. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты бер-берсенә кабул ителгән хокук актларын кул куелганнан соң җиде көн эчендә җибәрәләр.

4. Район Советы, Район Башлыгы Район Башкарма комитетына Район Башкарма комитеты Җитәкчесенә, Район Башкарма комитетының башка вазифаи затларына хокук актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү яки өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итергә хокуклы, шулай ук суд тәртибендә аларга шикаять белдерергә хокуклы.

5. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе Район Советына, Район Башлыгына Район Советы, Район Башлыгы хокук актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү яки өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итергә , шулай ук суд тәртибендә аларга шикаять белдерергә хокуклы.

6. Район Башлыгы Район Башкарма комитеты Җитәкчесенә Район Советы Регламенты билгеләгән тәртиптә Район Советының эш планын һәм Район Советы карарлары проектларын җибәрә.

7. Район Советы һәм аның органнары утырышларында, Район Башлыгы уздырган утырышларда Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасарлары яки аның вәкилләре киңәш хокукы белән катнашырга

хокуклы. Район Башкарма комитеты Дәүләт хезмәтендәге затлар язмача чакыру булган очракта, Район Советы утырышларында катнашырга бурычлы.

8. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе уздырган утырышларда Район Башлыгы, Район Советы депутатлары катнашырга хокуклы.

9. Районның икътисади һәм иҗтимагый үсеше процессы белән нәтиҗәле идарә итү максатыннан һәм аның халкы ихтыяҗларында Районның җирле үзидарә органнарына Районның җирле үзидарә вазифаи затларын, Районның җирле үзидарә сайлау органнары вәкилләрен, Район Советы депутатларын, шулай ук муниципаль учреждениеләрнең эшчеләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү, яңадан укытуны һәм квалификацияләрен үстерүне оештыру вәкаләтләре бирелә.

**52нче маддә. Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү**

1. Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге Россия Федерациясе Президенты билгеләгән тәртиптә раслана.

2. Татарстан Республикасы югары вазифаи шәхеснең (Татарстан Республикасы дәүләт властеның югары башкарма органы җитәкчесе) норматив хокук актлары белән Татарстан Республикасы бюджеты хисабыннан Районга иң яхшы күрсәткечләргә ирешүгә һәм күрсәткечләрне бүләкләүгә булышлык итү максатыннан, грантлар бүлеп бирү каралган булуы мөмкин.

**53нче маддә. Районның җирле үзидарә органнары арасында каршылыкларны чишү**

Районның җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен тормышка ашыру буенча каршылыклар килешү яки суд тәртибендә чишелә.

**VIIнче бүлек. Җирле үзидарәнең башка органнары һәм Районның муниципаль органнары**

**54нче маддә. Районның Контроль- хисап Палатасы**

1. Районның Контроль- хисап Палатасы Районның җирле үзидарә финанс контроленең даими эшләүче коллегиаль органы булып тора. Контроль- хисап Палатасы Район Советы белән хисаплаша.

2. Контроль- хисап Палатасы рәисе вазифасына Район Башлыгы тәкъдиме белән Район Советы тарафыннан биш елга билгеләнә. Контроль- хисап Палатасы рәисе үзенең вәкаләтләрен даими нигездә тормышка ашыра.

3. Контроль-хисап Палатасы рәисе һәм аудиторлары Районның җирле үзидарәсе вазифаи затлары булып тора. Контроль-хисап Палатасы рәисе Контроль-хисап Палатасы эшчәнлеген тормышка ашыра һәм аның эшчәнлеген оештыра, Контроль-хисап Палатасын дәүләт власте

органнарында һәм җирле үзидарә органнарында күрсәтә, Контроль-хисап Палатасының отчётларын, бәяләмәләрен һәм җавапларын имзалый.

4. Контроль- хисап Палатасының герблы мөһере һәм үзенең атамалары һәм Район гербы сурәте белән бланклары бар.

5. Контроль-хисап Палатасы эшчәнлеген финанслауны тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты классификациясе белән яраклаштырып Югары Ослан муниципаль районы бюджетында аерым юл белән карала.

6. Контроль- хисап Палатасы үзенең эшчәнлеген кануннар, әлеге Устав, Район Советы раслаган Контроль- хисап Палатасы турында Кагыйдәнамәгә таянып башкара.

**55нче маддә. Районның Финанс- бюджет Палатасы**

1. Районның Финанс-бюджет Палатасы Район бюджетының үтәлешен, Район бюджеты проектларын төзүне һәм аның үтәлеше турында отчётны тормышка ашыручы җирле үзидарәнең даими эшләүче финанс органы булып тора. Финанс-бюджет Палатасы Район Советы белән хисаплаша.

2. Финанс-бюджет Палатасы рәисе вазифасына Район Башлыгы боерыгы белән конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы итеп билгеләнә.

3. Финанс-бюджет Палатасы рәисе Районның җирле үзидарәсе вазифаи заты булып тора, Финанс-бюджет Палатасы эшчәнлеген тормышка ашыра һәм аның эшчәнлеген оештыра.

4. Финанс-бюджет Палатасының герблы мөһере һәм үзенең атамалары һәм Район гербы сурәте белән бланклары бар.

5. Финанс-бюджет Палатасы эшчәнлеген финанслауны тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджет классификациясе белән яраклаштырып Югары Ослан муниципаль районы бюджетында аерым юл белән карала.

6. Финанс-бюджет Палатасы үзенең эшчәнлеген кануннар, әлеге Устав, Район Советы раслаган Финанс-бюджет Палатасы турында Кагыйдәнамәгә таянып башкара.

**56нчы маддә. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы**

1. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы үзенең вәкаләтләре кысаларында муниципаль мөлкәт белән идарә итү, шул исәптән муниципаль район милеге булган акцияләр, хуҗалык оешмаларының устав капиталындагы өлешләр (кертем), кулланышта яки район карамагында булган җир кишәрлекләре белән идарә итү максатыннан оештырылган Район җирле үзидарәсенең даими эшләүче органы булып тора. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы Район Советы белән хисаплаша.

2. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе вазифасына Район Башлыгы боерыгы белән конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы итеп билгеләнә.

3. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Районның җирле үзидарәсе вазифаи заты булып тора, Районның җир һәм мөлкәт

мөнәсәбәтләре Палатасы эшчәнлеген тормышка ашыра һәм аның эшчәнлеген оештыра.

4. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасының герблы мөһере һәм үзенең атамалары һәм Район гербы сурәте белән бланклары бар.

5. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы эшчәнлеген финанслауны тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты классификациясе белән яраклаштырып Югары Ослан муниципаль районы бюджетында аерым юл белән карала.

6. Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы үзенең эшчәнлеген кануннар, әлеге Устав, Район Советы раслаган Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы турында Кагыйдәнамәгә таянып башкара.

**57нче маддә. Районның Сайлау комиссиясе**

1. Районның Сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнарына карамаган Районның муниципаль органы булып тора, үзенең функцияләрен тормышка ашыруны "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Канунының 28нче маддәсе белән туры китереп уздыра.

2. Районның Сайлау комиссиясе федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануны һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы билгеләгән тәртиптә һәм вакытта оештырыла.

3. Районның Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанслауны тәэмин итү чыгымнары Россия Федерациясе бюджеты классификациясе белән яраклаштырып район бюджетында аерым юл белән карала.

4. Районның Сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлегенең тәртибе һәм гарантияләр федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануны һәм әлеге Устав белән җайга сала.

**58нче маддә. Район Советы депутатының, Районның җирле үзидарә органының сайлап куелган әгъзаның, Районның җирле үзидарә органының сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең вәкаләтләрен тормышка ашыру гарантияләре**

1. Район Советы депутатының, җирле үзидарә органының сайлап куелган әгъзаның, җирле үзидарә органының сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең вәкаләтләрен тормышка ашыру гарантияләре федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп Район Уставы белән билгеләнә.

2. Даими нигездә муниципаль вазифа башкарган кешегә гарантияләр бирелә:

1) муниципаль хокук актлар белән туры китереп дәүләт хезмәтендәге вәкаләтләрен башкаруны тормышка ашыру өчен уңай шартлар;

2) канунга туры китереп, милек формаларына карамастан, җирле үзидарә органнарының, предприятие, учреждение һәм оешмаларның дәүләт хезмәтендәге кешеләре, Югары Ослан бюджеты хисабыннан тулысынча яки өлешчә финансланган, яки салым һәм мәҗбүри бурычларын түләү буенча ташламалары булган, яки Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан оештыручы сыйфатындагы җирле үзидарә органы тарафыннан беренче чиратта кабул итү хокукы;

3) Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары кабул иткән хокук актларына тоткарлыксыз керүгә хокук;

4) Югары Ослан муниципаль районы хокук актлары билгеләгән тәртиптә, Район территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнарыннан әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруга кирәк булган мәгълумат алырга, ә федераль кануннар белән каралган очракта – барлык милек формалары булган оешмалардан, җәмәгать оешмаларыннан һәм аларның дәүләт хезмәтендәге кешеләреннән мәгълумат алырга хокук;

5) вакытында һәм тулы күләмдә акчалата түләү алуга хокук;

6) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән тәэмин ителгән ял, ял көннәре һәм бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле төп һәм өстәмә ялга хокук;

7) муниципаль вазифа башкарган кешегә һәм аның гаиләсенә, шул исәптән муниципаль вазифа башкарган кеше пенсиягә чыкканнан соң медицина ярдәме күрсәтү;

8) муниципаль вазифа башкарган кешегә, үзенең вазифасын башкарган вакытта хезмәткә яраклылыгын югалткан очракта дәүләт социаль страхованиесенә;

9) Уставта билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, муниципаль вазифа башкарган кеше пенсия белән тәэмин ителергә, шулай ук федераль кануннарга туры китереп, муниципаль вазифа башкарган кеше, үзенең вазифасын башкарган вакытта үлгән очракта, аның гаиләсен пенсия белән тәэмин итү хокукы;

10) федераль кануннар белән, Югары Ослан муниципаль районы хокук актлары билгеләгән тәртиптә, шартларда һәм очракта үзенең вазифасын башкарган вакытта көчләү, янаулар һәм башка аның хокукларын бозган гамәлләрдән муниципаль вазифа башкарган кешене һәм аның гаиләсен яклау;

11) эш буенча командировкалар белән бәйле чыгымнарны каплау;

12) Югары Ослан муниципаль районы хокук актлары билгеләгән тәртиптә, үзенең вазифасын башкарган вакытта транспорт белән тәэмин итү, шулай ук эш буенча шәхси транспортын кулланган өчен компенсация .

Даими нигездә муниципаль вазифа башкарган кешегә депутат вазифаларын башкару, җирле үзидарә органының сайлап куелган әгъзаның, җирле үзидарә органының сайлап куелган дәүләт хезмәтендәге шәхеснең вәкаләтләре туктатылганнан соң, пенсия яше җиткәч, яки районның сайлап куелган органы билгеләгән тәртиптә, үзенең вазифасын башкарган вакытта хезмәткә яраклылыгын югалткан очракта, өстәмә социаль һәм башка гарантияләр бирелә. Район бюджеты акчасын тотуны күздә тоткан мондый гарантияләр, “Коррупциягә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ Федераль кануны, “Россия территориясеннән чиктә булган чит ил банкларында акча саклау һәм счёт ачу аерым категория шәхесләргә тыелуы турында”7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль кануны, “Дәүләт вазифасын башкаручы шәхесләрнең һәм башка шәхесләрнең чыгымнары белән керемнәре туры килүне контрольдә тоту турында ” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230-ФЗ Федераль кануннарында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазифасын үтәмәгән очраклар белән каралган нигез буенча әлеге затларның вәкаләтләре туктатылган очракта кулланылмый.

3. Даими булмаган нигездә муниципаль вазифа башкарган кешегә әлеге маддәнең 1нче пунктының 1-4 һәм 10нчы кече пунктларында каралган гарантияләр бирелә, Югары Ослан муниципаль районы хокук актлары билгеләгән тәртиптә эш буенча командировкалар белән бәйле чыгымнарнын компенсацияләү каралган.

4. Муниципаль вазифа башкарган кешеләргә вазифаларын башкару гарантиясе Югары Ослан бюджеты хисабына финанслана.

**59нчы маддә. Районның яңадан оешкан муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары турында**

Районның җирле үзидарә органнары структурасы авыл арасы территорияләрендә Районның яңадан оешкан муниципаль берәмлеге барлыкка килгән очракта, яки яңадан оешкан муниципаль берәмлеге үзгәртеп кору юлы белән барлыкка килгән очракта халык тарафыннан җирле референдумда яки муниципаль берәмлекнең Советы Карары белән билгеләнә һәм муниципаль берәмлек уставында беркетелә.

Районның яңадан оешкан муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне яңадан оешкан муниципаль берәмлек халкының тиешле инициативасы булган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары тәэмин итә.

Районның яңадан оешкан муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча җирле референдум, әлеге муниципаль берәмлекнең чикләрен билгеләү турында Татарстан Республикасы кануны көченә кергәннән соң бер ай эчендә җирле референдум үткәрүне яңадан оешкан муниципаль берәмлек халкыннан, җирле референдум үткәрү турында Татарстан Республикасы кануны һәм федераль канунннар билгеләгән тәртиптә барлыкка килгән, сайлау хокукы булган бер төркем инициатива белән чыккан очракта үткәрелә. Күрсәтелгән төркем муниципаль берәмлек халкының гомуми санының 3 процентыннан ким булмаган, сайлау хокукы булган халыкның имзаларын җыерга һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә имзалар кәгазен, җирле референдум үткәрү турында Татарстан Республикасы кануны һәм федераль канунннар билгеләгән тәртиптә һәм вакытта тапшырырга тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе җыелган имзаларның чын икәнен тикшерүче муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен формалаштыра, җирле референдум үткәрү вакытын билгели, шулай ук “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында ”Федераль кануны, Татарстан Республикасы кануны һәм федераль канунннар белән каралган, җирле референдум үткәрү буенча муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең башка вәкаләтләрен тормышка ашыра. Муницbackground берәмлек сайлау комиссиясенең вәкаләтләре “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына төп гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында” 12нче июнь, 2002нче ел, №67-ФЗ Федераль канунга туры китереп территотиаль сайлау комиссиясенә тапшырылырга мөмкин. Җирле референдум үткәрү турында гражданнар инициативасы булмаса, аны сайлаганнан соң, җирле үзидарә органы структурасы яңадан оешкан муниципаль берәмлекнең Совет Карары белән билгеләнә.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш Советы депутатларының саны һәм вәкаләтлек вакыты, шулай ук җирле референдум үткәрү турында гражданнар инициативасы булмаса, әлеге муниципаль берәмлекнең беренче башлыгын сайлау тәртибе, вәкаләтләре һәм вәкаләтлек вакыты Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнә.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарә органына сайлаулар ул оешканнан соң алты айдан да соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органына сайлауларны билгеләүче һәм Татарстан Республикасы кануны һәм федераль кануннар белән каралган сайлаулар үткәрү буенча муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләрен тормышка ашыручы яңадан оешкан муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен формалаштыра. Яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарә сайлау комиссиясенең вәкаләтләре Федераль канунга туры китереп территотиаль сайлау комиссиясенә тапшырылырга мөмкин.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары формалашканчы, яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарәнең территотияләрендә әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтлекләрне федераль кануннарга туры китереп, яңадан оешкан муниципаль берәмлек барлыкка килгән көнгә бу территорияләрдә әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкарган җирле үзидарә органнары тормышка ашыра.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлек барлыкка килгән көнгә бу территорияләрдә әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкарган җирле үзидарә органнары кабул иткән муниципаль хокук актлары федераль кануннарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы кануннарына һәм башка норматив хокук актларына, шулай ук яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары муниципаль хокук актларына каршы килмәгән өлешендә гамәлдә була.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары үзләренең компетенцияләре белән туры китереп, яңадан оешкан муниципаль берәмлек барлыкка килгән көнгә бу территорияләрдә Татарстан Республикасы дәүләт органнары белән, җирле үзидарә органнары белән, физик һәм юридик шәхесләр белән әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкарган җирле үзидарә органнарының хокуклы варисы булып тора. Хокуклы варис мәсьәләләре яңадан оешкан муниципаль берәмлек хокук актлары белән җайга салынырга тиеш.

Яңадан оешкан муниципаль берәмлекнең муниципаль хокук актларының, җирле үзидарә органнары тарафыннан алдан оешкан, яңадан оешкан муниципаль берәмлек барлыкка килгән көнгә бу территорияләрдә әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкарган җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлекләргә, муниципаль учреждениеләргә, предприятиләргә һәм оешмаларга карата хокуклы варис мәсьәләләрен җайга салганчы, яки алар катнашында, тиешле муниципаль берәмлекләр, муниципаль учреждениеләр, предприятиләр һәм оешмалар, элеккеге оештыру –хокук формаларын саклап , үзләренең эшчәнлекләрен тормышка ашыруны дәвам итәләр.

**VIIIнче бүлек. Районның җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль органнары эшчәнлегенең гражданлык-хокук һәм финанс нигезләре**

**60нчы маддә. Юридик шәхес хокукына ия булган Районның җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар**

1. Федераль кануннарга һәм әлеге Уставка туры китереп, юридик шәхес хокукы Район Советына һәм Район Башкарма комитетына, Финанс- бюджет Палатасына, Районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасына бирелә.
2. Район Советы карары белән Районның Контроль- хисап Палатасына, Районның Сайлау комиссиясенә, шулай ук Башкарма комитет структуралары белән туры китереп, аның аерым органнарына бирелә.

**61нче маддә. Юридик шәхес буларак Районның җирле үзидарә органнары**

1. Район исеменнән Район Башкарма комитеты Җитәкчесе мөлкәт һәм башка хокук һәм бурычларны ала һәм тормышка ашыра ала, судта ышанычнамәдән башка чыгыш ясый ала.
2. Район Башлыгы мөлкәт һәм башка хокук һәм бурычларны ала һәм тормышка ашыра ала, Район Советы, Район Башлыгы, депутатлар эшчәнлеген оештыруга юнәлтелгән Район бюджеты акчаларыннан файдаланганлыктан , шулай ук Район Советына беркетелгән муниципаль мөлкәттән файдаланганлыктан судта ышанычнамәдән башка чыгыш ясый ала.
3. Юридик шәхес хокукы бирелгән Районның җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен тормышка ашыру өчен барлыкка килгән муниципаль учреждениеләр булып торалар, һәм федераль кануннар билгеләгән тәртиптә юридик шәхес буларак дәүләт регистрациясен узарга тиеш.

**62нче маддә. Районның җирле үзидарә органнарын финанслау**

1. Районның җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнарны финанслау бары тик Район бюджетының үзенең кереме хисабына гына тормышка ашырыла.
2. Канун, әлеге Устав, Район Советы карары белән каралган очракта Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итүгә тотылган чыгымнарны финанслауны Россия Федерациясе бюджеты классификациясе белән яраклаштырып Югары Ослан муниципаль районы бюджетында аерым юл белән карала.

**IXнче бүлек. Район башлыгының һәм Районның муниципаль вазифаларын башкаручы башка шәхесләрнең иҗтимагый һәм башка гарантиеләре**

**63нче маддә. Даими эшләүче Район Башлыгы һәм аның урынбасары эшчәнлекләренең иҗтимагый һәм башка гарантиеләре**

1. Даими эшләүче Район Башлыгына һәм аның урынбасарына, бу Кагыйдәнамәгә яраклаштырып айлык акчалата түләү каралган.
2. Район Башлыгына һәм аның урынбасарына айлык акчалата түләү күләме Район Советы тарафыннан билгеләнә. Район Советының шул елга Район бюджеты турында карарына яраклаштырып, инфляция (куллану бәяләре) дәрәҗәсен исәпкә алып, айлык акчалата түләү күләме ел саен арта (индексацияләнә).
3. Кануннарга яраклаштырып, даими эшләүче Район Башлыгына һәм аның урынбасарына 30 календарь көн күләмендә түләүле ял һәм эш стажына карап дәвалануга пособие түләү, командировка чыгымнарын кайтару, башка түләүләр белән өстәмә ял бирелә.
4. Кануннарга яраклаштырып, даими эшләүче Район Башлыгы һәм аның урынбасарының вәкаләтлек срогы аларга гомуми һәм өзлексез стажына санала, яки хезмәт срогы, белгечлекләре буенча хезмәт стажы булып санала.
5. Кануннарга һәм бу Кагыйдәнамәгә яраклаштырып, хезмәткәрләрне пенсия белән тәэмин итү өчен билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә, Районның муниципаль Район Башлыгы һәм аның урынбасары тиешле еллар эшләгән өчен пенсия белән тәэмин ителергә хокуклы.
6. Район Башлыгына һәм аның урынбасарына үз вәккаләтләрен башкару өчен җиһаз һәм элемтә чаралары булган эш бүлмәсе, шулай ук Район Советы карары белән билгеләнгән аларның эшчәнлегенең башка гарантиеләре каралган.

**64нче маддә. Район Советы депутатының, башка дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең эшчәнлегенең иҗтимагый һәм башка гарантиеләре**

1. Азат ителмичә эшләүче Район Советы депутатына Район Советының аерым йөкләмәләрен үтәгән вакытта Район Советы билгеләгән күләмдә акчалата түләү каралган. Компенсация, Кануннарга яраклаштырып, Районда уртача хезмәт хакы күләменнән исәпләнгән сәгатьләп түләүне, шулай ук командировка чыгымнарын түләүне үз эченә ала.
2. Үзенең вәкаләтләрен азат ителеп башкаручы Район Башлыгы урынбасарына, Район Башлыгы вазифаларын башкарганда, бу Кагыйдәнамәдә каралганча, Район Башлыгының айлык акчалата түләү күләменең 90% күләмендә акча түләү каралган.
3. Кануннарга, Район Советы карарларына яраклаштырып, Районның Контроль-хисап Палатасы аудитрларына һәм Районның Сайлау комиссиясе әгъзаларына бу органнарның эшендә катнашкан вакытта акчалата түләү каралган.

**65нче маддә. Район Башлыгы, Район Советы депутатларының иминлеге гарантияләре**

1. Район Советы депутатлары, шул исәптән Район Башлыгы хокукларын, аларны җинаять һәм административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлаганда, кулга алганда, төнтү оештырганда, сорау алганда, аларга карата җинаять- процессуаль һәм административ – процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатка карата, аның эш бүлмәсен, багажын, шәхси

һәм эш транспорт чараларын, язышу, кулланган элемтә чараларын, аңа кагылышлы документларны тикшерү буенча оператив- эзләү чаралары үткәргәндә, гарантияләү федераль кануннар белән билгеләнә.

2. Кануннарга яраклаштырып, Район Советы депутаты тавыш биргәндә әйтелгән фикер, позиция өчен, аның Район Башлыгы статусына туры килгән башка гамәлләре, шул исәптән аның вәкаләтләре беткәнче, җинаять һәм административ җаваплылыкка тартыла алмый. Бу кагыйдәнамә Район Советы депутаты тарафыннан халык алдында кимсетү, яла ягу һәм башка федераль кануннар белән җаваплылыкка тарту каралган тәртип бозулар булган очракларга карамый.

**Хнчы бүлек. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең җаваплылыгы**

**66нчы маддә. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең җаваплылыгы**

Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр федераль кануннарга туры китереп, Район халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында җаваплы булалар.

**67нче маддә. Җирле үзидарә органнары Район Советы депутатларының Район халкы алдында җаваплылыгы**

1. Районның җирле үзидарә органнары, Район Советы депутатларының, шул исәптән Район Башлыгының әлеге депутатның Район халкы алдында җаваплылыгы аны сайлаган халык ышанычын югалту нәтиҗәсендә башлана.

2. Ышаныч югалткан депутат , шул исәптән сайлап куелган орган депутаты буларак Район Башлыгы бу Кагыйдәнамә һәм Район Уставына яраклаштырып, шул җирлекнең сайлаучылары тарафыннан чакыртып алына ала.

**68нче маддә. Районның сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең дәүләт алдындагы җаваплылыклары**

Федераль кануннарга туры китереп, Район Советының, Район Башлыгының дәүләт алдындагы җаваплылыгы Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституция кануннарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы кануннарын һәм бу Уставны бозган очракта чыгарылган суд карары нигезендә башлана, шулай ук Районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә тормышка ашырмаган очракта башлана.

**69нчы маддә. Районның сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы**

Районның сайлап куелган органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы федераль кануннар белән билгеләнгән тәртиптә бшлана.

## XIнче бүлек. Районның муниципаль хокук актлары

### 70нче маддә. Районның муниципаль хокук актлар системасы

1. Районның муниципаль хокук актлар системасына керәләр:
1) Район Уставы;
2) җирле референдумда кабул ителгән хокук актлары;
3) Район Советының норматив һәм башка хокук актлары;
4) Район Башлыгының, җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтендәге затлары һәм башка органнарның бу Устав белән каралган норматив һәм башка хокук актлары.

2. Район Уставы һәм җирле Референдумда кабул ителгән карар килеш ясалган хокук актлары муниципаль хокук актлар системасында югары юридик көчкә ия булган актлар булып тора, туры көчкә ия һәм бөтен Район территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокук актлары бу Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокук актларына каршы килергә тиеш түгел.

3. Җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге затлары һәм органнары кабул иткән муниципаль хокук актлары бөтен Район территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш.

4. Муниципаль хокук актларын үтәмәгән өчен халык, оешма җитәкчеләре, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары дәүләт хезмәтендәге затлар, федераль кануннарга һәм административ хокук бозулар турындагы Татарстан Республикасы Кодексына яраклаштырып, җаваплы була.

5. Районның муниципаль хокук актлары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция кануннарына, федераль кануннарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы кануннары һәм башка норматив хокук актларына каршы килергә тиеш түгел.

6. Муниципаль хокук актлары, бу органнар яки вазифалар юкка чыгарылганда, муниципаль хокук актларын кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары тарафыннан юкка чыгарыла яки аларның гамәлдә булу вакыты туктатылып тора, яки бу органнарның һәм дәүләт хезмәтендәге затларның вәкаләтләре исемлеге җирле үзидарә органнары яки дәүләт хезмәтендәге затлары тарафыннан үзгәрсә, шулай ук суд тарафыннан юкка чыгарыла, ә федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләре җирле үзидарә органнары тарафыннан тормышка ашырылуын җайга салган өлешендә, Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары белән, яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары белән тормышка ашырылганда юкка чыгарыла.

Суд карары нигезендә, Татарстан Республикасының Район статусын билгеләү турында яңа кануны гамәлгә кергәнче, Татарстан Республикасының Район статусын билгеләү турында кануны гамәлдән

чыккан дип табылуы, суд тәртибендә муниципаль хокук актларының суд карары көченә кергәнче кабул ителгән Район статусын билгеләү турында кануны гамәлдән чыккан дип табылуы нигез булып тора алмый.
Норматив характерда булмаган муниципаль хокук акты аны кабул иткән җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе тарафыннан эшмәкәрләрнең хокукларын саклау буенча вәкаләтлекләр турында канунга туры китереп бирелгән Россия Федерациясенең эшмәкәрләрнең хокукларын саклау буенча вәкаләтлекләр буенча канунына туры китереп, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилнең тиешле боерыгы алынган очракта, һичшиксез туктатыла. Алынган боерыкны үтәү турында муницпаль район Башкарма комитеты яки район җирле үзидарсенең дәүләт хезмәтендәге кешесе Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкиленә өч көн эчендә, ә Район Советы – алар карар кабул иткән көннән соң өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итергә тиеш.

**71нче маддә. Гражданнарның туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар**

1. Аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне чишү турыдан-туры Район халкы тарафыннан җирле референдумда белдерелгән туры ихтыяр белдерү юлы белән тормышка ашырыла.

2. Район халкы тарафыннан туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен өстәмә муниципаль хокук акты кабул итү (чыгару) кирәк икән, әлеге актны кабул итү (чыгару), аларның компетенцияләренә кергән Районның җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе, референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергәннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш.

3. Район халкы тарафыннан туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен кирәкле булган муниципаль хокук актын бастырып чыгару сроклары бозылу, Район Башлыгын чакыртып алу, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең контракт нигезендә тормышка ашырылган вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга яки Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга җирлек булып тора.

**72нче маддә. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокук актларының төрләре**

1. Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр аларга йөкләтелгән вәкаләтләрне башкарганда түбәндәге муниципаль хокук актлары чыгаралар:

1) Район Советы- Район Советы карарлары;

2) Район Башлыгы- Район Башлыгы карарлары һәм әмерләре;

3) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе - Район Башкарма комитеты Җитәкчесе карарлары һәм әмерләре.

2. Районның җирле үздарә дәүләт хезмәтендәге башка шәхесләр үзләренең вәкаләтләре кысаларында, аларның статусын билгеләүче бу Устав белән,

башка муниципаль хокук актлары белән билгеләнгәнчә, әмерләр һәм боерыклар чыгаралар.

## 73нче маддә. Муниципаль хокук актларын әзерләү

1. Муниципаль хокук актлары проектлары Район Башлыгы, Район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнрның инициатив төркеме, шулай ук Районның Контроль –хисап Палатасы, Районның Финанс – бюджет Палатасы, Районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан аларны алып бару мәсьәләләре буенча кертелә ала.

2. Муниципаль хокук актлары проектларын кертү тәртибе, аңа беркетелә торган документларның исемлеге һәм формасы әлеге проект аларның карап чыгуына кертелгән җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе норматив хокук актлары белән билгеләнә.

## 74нче маддә. Район Советының хокук актлары

1. Район Советы, аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча, Район территориясендә үтәлергә тиешле кагыйдәләрне билгели торган карарлар кабул итә, Район Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итә, шулай ук Район Советы Регламентын һәм Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар һәм Федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары, Район Уставы белән аның компетенциясенә караган башка сораулар буенча карарлар кабул итә.

2. Район Советы карарлары бу Кагыйдәнамә, кануннар билгеләгән очраклардан кала, билгеләнгән Район Советы депутатлары санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3. Җирле салым һәм җыюларны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгаруны, Район бюджеты акчаларын тотуны тормышка ашыруны күздә тоткан Район Советы карарлары Район Советы тикшерүенә Район Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча яки аның бәяләмәсе булганда кертелә ала. Күрсәтелгән бәяләмә Район Советына Район Башкарма комитетына проект карары тапшырылгач утыз көн эчендә тапшырыла.

4. Район Советы карарлары Район Башлыгы тарафыннан аларны кабул иткәннән соң өч көн эчендә имзалана һәм бу Уставта билгеләнгән тәртиптә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

## 75нче маддә. Район Башлыгының хокук актлары

Район Башлыгы канунда, бу Уставта, Район Советы карарларында билгеләгәнчә үзенең вәкаләтләре кысаларында, Район Советы аппараты, Район Башлыгы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокук актлары чыгара, Район Башлыгының карарларына һәм боерыкнамәләренә кул куя.

## 76нчы маддә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе хокук актлары

Район Башкарма комитеты Җитәкчесе канунда, бу Уставта, Район Советы карарларында билгеләгәнчә, үзенең Район Башкарма комитеты вәкаләтләре кысаларында, Район җирле үзидарә органнарына федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән тапшырылган дәүләт вәкаләтлекләрен тормышка ашыру белән бәйле булган карарлар кабул итә, шулай ук Район Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча боерыклар чыгара.

## 77нче маддә. Муниципаль хокук актларының басылып чыгу һәм гамәлгә керү тәртибе

1. Район Советы карарлары, карар белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, Район Башлыгы аларга кул куйгач, 10 көн узганнан соң үз көченә керә.

Район Советының салым һәм җыюлар турындагы хокук актлары Россия Федерациясе Салым кодексына туры китереп үз көченә керә.

Район Советының Район Уставын кабул итү һәм бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары федераль кануннарда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Район Башлыгының, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең, җирле үзидарә дәүләт хезмәтендәге затларның хокук актлары, бу актлар белән башка нәрсә каралмаса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм гражданин хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокук актлары, аларны рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокук актының реквизитлары булырга тиеш: исеме, кул кую көне (Район Советы кабул иткән хокук актларына –Район Советы кабул иткән көн), регистрация номеры, хокук актына кул куйган дәүләт хезмәтендәге затның исеме.

5. Район Советының, федераль кануннар белән аларны тарату чикләнгән муниципаль хокук актларыннан кала, Район Советы, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән Район бюджеты турындагы карары, аның үтәлеше турында отчёты, җирле салым һәм җыемнарны билгеләү турында, Район Советы Регламенты турында, башка норматив хокук актлары кул куелганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Рәсми рәвештә, җирле референдумны билгеләү турында, Район чикләрен үзгәтү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре турында, Район Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау турында, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм аның урынбасарларын сайлау турында һәм канунга туры китереп башка норматив булмаган хокук актлары басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Норматив булмаган хокук актлары, кануннарга һәм бу Уставка туры китереп рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерелү) мөһим булмаганлыктан, аны чыгарган Районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге затлар чыгарган карар буенча бастырылып (халыкка җиткерелә) чыгарыла ала.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткерелгәндә) муниципаль хокук актларының реквизитлары күрсәтелә.

9. Муниципаль норматив һәм норматив булмаган хокук актларын рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) хокук акты текстын “Идел яңалыклары” район гәҗитендә, яки хокук акты текстын Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгару аша тормышка ашырыла.

Рәсми сайтта бастырып чыгарудан (халыкка җиткерүдән) тыш муниципаль норматив һәм норматив булмаган хокук актлары Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырыла ала.

10. Муниципаль хокук актларын бастырып чыгарган вакытта массакүләм басма мәгълумат чарасының чыгу вакыты күрсәтелергә тиеш.

Кеше һәм гражданин хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокук актлары, җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль предприятие һәм учреждение хокук статусларын билгели торган хокук актлары Район Башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына Татарстан Республикасы норматив хокук актларының регистрына кертү өчен юнәлтелә.

## XIIнче бүлек. Районның муниципаль хезмәте

### 78нче маддә. Районның муниципаль хезмәте

1. Районның муниципаль хезмәте –хезмәт килешүе (контракт) төзү юлы белән башкарыла торган Районның муниципаль хезмәте вазифаларында даими нигездә тормышка ашырыла торган гражданнарның профессиональ эшчәнлеге.

2. Муниципаль хезмәткәрләр өчен яллаучы булып, алар исеменнән яллаучы вәкаләтләрен тормышка ашырган яллаучы (эш бирүче) вәкилләре, Районның җирле үзидарә органнары тора.

3. Яллаучы (эш бирүче) вәкил булып Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, башка Район җирле үзидарә органы җитәкчесе яки яллаучы (эш бирүче) вәкиле вазифаларын башкаручы вәкаләтле шәхес була ала.

### 79нчы маддә. Районның муниципаль хезмәте вазифалары

1. Районның муниципаль хезмәте вазифасы - Районның җирле үзидарә органындагы, Район Уставына туры китереп, Район җирле үзидарәсе органы, Районның башка муниципаль органнары яки шәхесләре, яки муниципаль вазифа башкаручы вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча билгеләнгән хезмәт вазифалары белән барлыкка килгән Районның башка муниципаль органнарында оешкан вазифа.

2. Районның муниципаль хезмәте вазифалары Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары реестрына туры китереп Район муниципаль хокук актлары белән билгеләнә.

3. Районның җирле үзидарә органы, Районның Сайлау комиссиясе аппараты штаты расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан

Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазифалары исемнәре кулланыла.

**80нче маддә. Районның муниципаль хезмәт вазифаларының классификациясе**

1. Районның муниципаль хезмәт вазифалары түбәндәге төркемнәргә бүленә:
1) югары муниципаль хезмәт вазифалары;
2) баш муниципаль хезмәт вазифалары;
3) әйдәп баручы муниципаль хезмәт вазифалары;
4) өлкән муниципаль хезмәт вазифалары;
5) кече муниципаль хезмәт вазифалары.
2. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазифалары һәм дәүләт граждан хезмәт вазифалары бәйләнеше, тиешле Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазифалары һәм дәүләт граждан хезмәт вазифаларына квалификацион таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнә.

**81нче маддә. Районның муниципаль хезмәткәрләренең дәрәҗәләр төркемнәре**

1. Районның муниципаль хезмәткәрләренә дәрәҗәләр төркемнәре бирелә һәм муниципаль хезмәткәрне профессиональ әзерләү дәрәҗәсе хезмәт вазифасын башкару өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.
2. Муниципаль хезмәткәрләренә түбәндәге дәрәҗәләр төркемнәре бирелә:
югары муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы – 1,2 яки 3нче дәрәҗәле хакыйкый муниципаль киңәшче;
баш муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль киңәшче;
әйдәп баручы муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт киңәшче;
өлкән муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт референты;
кече муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт сәркатибе.
3. Муниципаль хезмәт вазифаларын алда күрсәтелгән төркемнәргә кертү муниципаль хезмәт Реестры белән туры китереп тормышка ашырыла.
4. Муниципаль хезмәткәрләргә дәрәҗәләр төркемнәре бирү тәртибе, һәм муниципаль хезмәткәрне башка муниципаль хезмәткә күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән алынган очракта аларны саклау, гамәлдәге канунга туры китереп тормышка ашырыла.

**82нче маддә. Районның муниципаль хезмәткәре**

1. Районның муниципаль хезмәткәре булып, федераль кануннар белән һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп, Район муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә Районның муниципаль хезмәт

вазифалары буенча вазифа башкаручы, Район бюджетыннан түләнгән хезмәт хакы алып эшләүче гражданин тора.

2. Районның җирле үзидарә органнары һәм Районның башка муниципаль оешмалары эшчәнлегеен техник тәэмин итү буенча вазифалар башкарган затлар Районның муниципаль хезмәте вазифаларын башкара алмый һәм муниципаль хезмәткәр булмый.

**83нче маддә. Районның муниципаль хезмәтенә керү, аны узу һәм туктату тәртибе**

1. Районның муниципаль хезмәтенә керү “Муниципаль хезмәт турында” Татарстан Республикасы Кануны һәм Федераль канунда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең хезмәт турында канунына туры китереп тормышка ашырыла.

2. Муниципаль хезмәтне узу, муниципаль хезмәт белән идарә итү, муниципаль хезмәт вазифаларына таләпләр , муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр гамәлдәге канунга туры китереп Районның муниципаль хезмәт турында Кагыйдәнамәсе белән билгеләнә.

3. Гражданин муниципаль хезмәт вазифалары буенча дәүләт хезмәтендәге вазифаларны башкару мөмкинлегенә юл куймаучы законлы көченә кергән суд карары буенча җәзага тартылган очракта, муниципаль хезмәткә алына алмый, шулай ук муниципаль хезмәттә була алмый.

4. Муниципаль хезмәтнең гомуми дәвамлылыгын билгеләү һәм муниципаль хезмәт стажы тәртибен билгеләү һәм хезмәт эшчәнлегенең башка вакытларын кертү, Районның муниципаль хезмәт турында Кагыйдәнамәсе һәм гамәлдәге канун белән җайга салына.

5. Россия Федерациясенең хезмәт турында кануны белән каралган дәлилләрдән тыш, муниципаль хезмәткәрне эштән алу Районның муниципаль хезмәт турында Кагыйдәнамәсе белән һәм гамәлдәге кануннарда каралган дәлилләр буенча эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкил инициативасы буенча тормышка ашырыла ала.

6. Муниципаль хезмәткәрнең пенсиягә чыгу вакыты гамәлдәге канун белән билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәт вазифасында булуның иң зур яше – 65 яшь. Муниципаль хезмәт вазифасында булуның иң зур яшенә җиткән муниципаль хезмәткәрнең Районның муниципаль хезмәтендә булу вакытын озынайту рөхсәт ителә. Муниципаль хезмәткәрнең Районның муниципаль хезмәтендә булу вакытын бер тапкыр озынайту бер елга гына рөхсәт ителә.

**84нче маддә. Районның муниципаль хезмәткәре хокуклары һәм бурычлары**

1. Районның муниципаль хезмәткәре хокуклары һәм бурычлары гамәлдәге канун белән туры китереп, Районның җирле үзидарә органнары хокук актлары белән билгеләнә.

**85нче маддә. Районның муниципаль хезмәте белән бәйле чикләүләр**

Районның муниципаль хезмәте белән бәйле чикләүләр гамәлдәге канун белән туры китереп, Районның җирле үзидарә органнары хокук актлары белән билгеләнә.

### 86нчы маддә. Районның муниципаль хезмәткәрен бүләкләү

1. Районның муниципаль хезмәткәренә үзенең дәүләт хезмәтендәге вазифаларын уңышлы һәм намус белән башкарган өчен, мактауга лаек итеп һәм озак вакытлы хезмәте өчен, мөһим һәм катлаулы махсус йөкләмәләрне үтәгән өчен бүләкләү каралган.
2. Районның муниципаль хезмәткәрен бүләкләү төрләре һәм аны куллану тәртибе гамәлдәге канун белән туры китереп, Районның җирле үзидарә органнары хокук актлары белән билгеләнә.
3. Районның муниципаль хезмәткәрен грамота белән бүләкләү тәртибе һәм шартлары Район Советы карары белән билгеләнә.

### 87нче маддә. Районның муниципаль хезмәткәренең дисциплина җаваплылыгы

1. Районның муниципаль хезмәткәре дисциплинар хата җибәргән өчен - Районның муниципаль хезмәткәре гаебе белән аңа йөкләнгән хезмәт вазифаларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен- эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкил түбәндәге дисциплинар җәза кулланырга мөмкин:
1) кисәтү;
2) шелтә;
3) тиешле дәлилләр буенча Районның муниципаль хезмәтеннән чыгару.
2. Дисциплинар хата җибәргән Районның муниципаль хезмәткәре, аның дисциплинар җаваплылыгы турында мәсьәлә хәл ителгәнче, хезмәт хакын саклап, вакытлыча (бер айдан артмаска тиеш) хезмәт вазифаларын башкарудан азат ителә ала.
3. Дисциплинар җаваплылык куллану тәртибе һәм аны алу тәртибе хезмәт кануны белән билгеләнә.

### 88нче маддә. Районның муниципаль хезмәткәренә бирелгән гарантияләр

1. Районның муниципаль хезмәткәренә үзенең хезмәт вазифаларын башкарган вакытта гамәлдәге канун белән билгеләнгән гарантияләр каралган.
2. Районның муниципаль хезмәткәренә Россия Федерациясенең хезмәт турында кануны белән билгеләнгәнчә, хезмәткәрләргә оешма ябылган очракта алар эштән алынса, эшчеләр саны яки штаты кыскартылса, башка гарантияләр каралган.
3. Районның муниципаль хезмәт турында Кагыйдәнамәсе белән Районның муниципаль хезмәткәренә өстәмә гарантияләр каралырга мөмкин.
4. Пенсия белән тәэмин итү өлкәсендә Районның муниципаль хезмәткәренә гамәлдәге канунда билгеләнгән тәртиптә дәүләт граждан хезмәткәре хокуклары тулы күләмдә карала.
5. Районның муниципаль хезмәткәренә дәүләт пенсиясе күләмен билгеләү, Россия Федерациясе субъекты канунында билгеләгән, Районның муниципаль

хезмәт вазифалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының бәйләнеше белән тормышка ашырыла. Районның муниципаль хезмәткәренең дәүләт пенсиясе максималь күләме Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә туры килгән вазифалары буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре пенсиясеннән артып китергә тиеш түгел.

6. Районның муниципаль хезмәткәре, үзенең вазифасын башкарган вакытта үлгән очракта, шул исәтән Районның муниципаль хезмәтеннән киткән очракта, гамәлдәге канун белән билгеләнгәнчә, аның гаиләсе караучысын югалткан очрак буенча пенсия алырга хокуклы.

**89нчы маддә. Районның муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү**

1. Районның муниципаль хезмәткәренә Татарстан Республикасы кануны билгеләгән, муниципаль хезмәттә аның вазифасына туры китереп вазифа окладын акчалата түләү итеп, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр башкарыла.

2. Вазифа окладын күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны тормышка ашыру, гамәлдәге кануннар белән башка нәрсә каралмаган булса, мөстәкыйль рәвештә Районның норматив-хокук актлары белән билгеләнә.

3. Айлык вазифа окладын Район Советының шул елга Район бюджеты турында карарына яраклаштырып, инфляция (куллану бәяләре) дәрәҗәсен исәпкә алып, айлык акчалата түләү күләме ел саен арта (индексацияләнә).

4. Районның муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү күләме Татарстан Республикасы канунында каралган соңгы нормативлар белән туры китереп билгеләнә.

**XIIIнче бүлек. Районның икътисади нигезе**

**90нчы маддә. Районның икътисади нигезе**

Районның икътисади нигезен Районның муниципаль милкендә булган мөлкәт, Район бюджеты акчасы, шулай ук Районның мөлкәт хокуклары тәшкил итә.

**91нче маддә. Районның муниципаль мөлкәте**

1. Муниципаль берәмлекләрнең милкендә була ала:

1) әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән билгеләнгән очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук әлеге Уставның 6нчы маддәсе 3нче пунктында каралган тәртиптә аларга җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) Район Советы Карары белән туры китереп җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә вазифаи затлары, муниципаль

хезмәткәрләр, муниципаль предприятие һәм учреждение эшчеләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;
4) җирле үзидарә органнарына федераль кануннар белән кирәкле мәсьәләләрне чишү өчен аларны чишү хокукы бирелгән мөлкәт, һәм алар әһәмиятле булган мәсьәләләргә карамаган очракта;
5) федераль кануннарга туры китереп башка мөлкәт.

**92нче маддә. Районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, аны куллану һәм аннан файдалану**

1. Районның җирле үзидарә органнары, әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә, вәкаләтләрне чикләүне исәпкә алып, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга һәм аларга туры китереп кабул ителгән норматив – хокук актларына туры китереп, Район исеменнән мөстәкыйль рәвештә муниципаль мөлкәткә ия булалар, аны кулланалар һәм файдаланалар.
2. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне вакытлыча яки даими кулланырга физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт власте органнарына, һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирергә хокуклы, тартып алырга, федераль кануннарга туры китереп башка килешүләр ясарга хокуклы.
3. Районның җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте башкарма властеның федераль органы вәкаләтлеге билгеләгән тәртиптә муниципаль мөлкәтнең реестрларын алып бара.

**93нче маддә. Районның муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары**

1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль кануннарга туры китереп Район Советы карарлары белән билгеләнә.
2. Муниципаль мөлкәтне куллану һәм хосусыйлаштырудан кергән керем Район бюджетына керә.

**94нче маддә. Муниципаль предприятие, учреждение һәм хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Районның җирле үзидарә органнары әлеге Устав белән билгеләнгән үзләренең вәкаләтләре кысаларында муниципаль предприятие һәм учреждениеләр төзи, үзгәртеп кора һәм бетерә ала, шул исәптән әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне башкару өчен кирәк булган муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре төзүдә катнаша ала.
2. Районның җирле үзидарә органнары Район исеменнән муниципаль учреждениеләрнең бурычлары буенча субсидиар җавап бирәләр һәм федераль кануннар билгеләгән тәртиптә аларның үтәлүен тәэмин итәләр.

**95нче маддә. Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган муниципаль предприятие, учреждение һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре**

Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган муниципаль предприятие, учреждение һәм оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән башка нәрсә билгеләнмәгән булса, килешү нигезендә төзелә.

## XIVнче бүлек. Районның финанс нигезе

### 96нчы маддә. Районның бюджеты

1. Районның үз бюджеты бар.
2. Район бюджеты Район Советы тарафыннан муниципаль хокук акты формасында эшләнә һәм раслана.
3. Район бюджетында җирле үзидарә органнарының Район өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруга юнәлтелгән чыгымнары аерым күздә тотыла, һәм Татарстан Республикасы кануннары һәм федераль кануннар белән аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан тормышка ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләре, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр хисабына тормышка ашырылган Район бюджетының тиешле чыгымнары аерым күрсәтелә.
4. Район җирле үзидарә органнары федераль кануннар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив- хокук актлары билгеләгән тәртиптә дәүләт властеның федераль органнарына һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт органнарына Район бюджеты үтәлеше турында отчёт тапшыралар.

### 97нче маддә. Районда бюджет процессы

1. Район бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту Район җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарыла. Район бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль кануннар һәм алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы кануннарына туры китереп тормышка ашырыла.
2. Район бюджеты проекты, Район бюджетын раслау турында Район Советы карары, аның үтәлеше турында еллык отчёт, Район бюджетының үтәлеше барышы турында квартал отчёты һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль учреждение эшчеләренең саны турында, аларны тотуга киткән фактик чыгымнарын күрсәткән мәгълумат рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
3. Район Советының җирле салымнар турында муниципаль хокук актларына үзгәрешләр кертү турында норматив- хокук актлары, Район Советының Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет чыгымнарын үзгәртүгә китерүче бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы алдагы финанс елында һәм планлы вакыт эчендә көченә керүче муниципаль хокук актлары, алдагы финанс елында һәм планлы вакыт эчендә көченә керүче

муниципаль хокук актларын Район Советына керткән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Район бюджеты проекты өч елга төзелә һәм раслана (алдагы финанс елында һәм планлы чорга).

5. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Район бюджеты проекты Районның иҗтимагый-икътисадый үсешен алдан әйтүгә таянып Районның чыгым йөкләмәләрен финанс тормышка ашыру нигезендә төзелә.

6. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Район бюджеты проекты Район Башкарма комитеты билгеләгән Россия Федерациясе Бюджет кодексы, аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставка туры китерелгән тәртиптә һәм вакытта төзелә.

7. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен билгели торган (бюджет сәясәтенә таләпләр) Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламалары кагыйдәнамәләрендә;

- бюджет сәясәтенең һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрендә;

- Россия Федерациясенең таможня –тариф сәясәтенең төп юнәлешләрендә;

- иҗтимагый-икътисадый үсешен алдан әйтүдә;

- бюджетны алдан әйтүдә (бюджетны алдан әйтү проекты, бюджетны алдан әйтү үзгәреше проекты ) озак срокка;

- муниципаль программаларда (муниципаль программалар проекты, әлеге программаларның үзгәреше проекты).

8. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Район бюджеты турында карарда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль кануннар һәм алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Район Советы муниципаль хокук актлары (бюджет турында карардан кала) билгеләгән тәртиптә, бюджетның керемнәренең төп күләме, чыгымнарының төп күләме, бюджет дефициты , шулай ук башка күрсәткечләр бюджетның төп тасвирламасы булырга тиеш.

9. Алдагы финанс елында һәм планлы чорга Район бюджеты турында карарда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән туры китереп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджеты турында Татарстан Республикасы кануны, Татарстан Республикасы кануны һәм муниципаль хокук актлары белән билгеләнмәгән очракта, җирлекләр бюджеты арасында керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш, шулай ук алдан әйтелгән Районның керем бюджеты күләме төркемнәр, төркемчәләр һәм маддәләр буенча керемнең коды төре буенча булырга тиеш.

10. Район бюджеты турында карар белән расланалар:

- Район бюджеты керемнәренең төп идарәчеләре исемлеге;

- Район бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының төп идарәчеләре исемлеге;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорга бюджет чыгымнарын классификацияләүнең чыгымнары төрләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан маддәләр арасында ассигновать ителгән бюджет акчасын бүлү;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорга бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

- ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән ассигновать ителгән бюджет акчасының гомуми күләме;

- алдагы финанс елында һәм планлы чорда Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган һәм (яки) башка бюджетларга бирелгән бюджетара трансфертлар күләме;

- Район бюджетының шартлы раслана торган (расланган) чыгымнарының гомуми күләме планлы чорның беренче елына Район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең 2,5 процентатан ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган бюджетара трансфертлар хисабыннан каралган, тиешле максатларга каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмаганда), планлы чорның икенче елына Район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең 5 процентатан ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясенең бюджет системасының башка бюджетлардан алынган бюджетара трансфертлар хисабыннан каралган, тиешле максатларга каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмаганда);

- алдагы финанс елына һәм планлы чорына Район бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары;

- алдагы финанс елыннан соң килгән һәм планлы чорның елыннан соң елның 1нче гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген күрсәтеп;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Район Советы муниципаль хокук актларына туры китереп билгеләнгән Район бюджетының башка күрсәткечләре.

11. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты турында карар проекты планлы чорның расланган бюджетының планлы параметрларын үзгәртү юлы белән һәм планлы чорга бюджет проектының икенче елы параметрларын аларга өстәү юлы белән раслана.

Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты турында карар проекты планлы чорның расланган бюджет күрсәткечләренә ачыклык кертә һәм планлы чорга төзелүче бюджетның икенче елы күрсәткечләрен раслый.

Районның расланган бюджетының планлы чорының параметрларына ачыклык кертү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты турында карар проектын карап чыгу кирәк булган күрсәткечләргә ачыклык кертүне раслау;

2) Район бюджеты чыгымнары ведомство структурасының расланган күрсәткечләрен арттыру яки киметү турында раслау, яки Район бюджеты чыгымнарының өстәмә максатчан маддәләре һәм (яки) төркемнәре буенча аңа бюджеттан бүлеп бирелгән акча кертүне раслау.

12. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты турында карар проекты белән беррәттән Район Советына тәкъдим ителә:

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджет сәясәтенең һәм Район салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- шушы финанс елының узган вакыты буенча Районның иҗтимагый – икътисадый үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм Районның иҗтимагый – икътисадый үсешенең шушы финанс елына көтелгән нәтиҗәләре;

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Районның иҗтимагый – икътисадый үсеше турында алдан әйтү;

- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Районның консолидир бюджетының төп тасвирламалары турында (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет җитешмәү ) алдан әйтү;

- Район бюджеты проектына аңлатма язуы;
- бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методика проектлары) һәм исәп – хисаплары;
- алдагы финанс елы ахырына һәм планлы чорның  һәм елының ахырына муниципаль бурычның өске чиге;
- алдагы финанс елына һәм планлы чорга бюджет кредитлары бирү программасы проекты;
- шушы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;
- Районның сайлап куелган органнары, суд системасы, муниципаль финанс тикшерү органнары тәкъдим иткән, Районның сайлап куелган органнары тарафыннан төзелгән, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата Районның Финанс-хисап Палатасы белән килешмәүчәнлекләр килеп чыккан очракта күрсәтелә торган  күрсәтелгән органнарның бюджет сметасы проектлары;
- алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты керемнәрен классификацияләү һәм  Район бюджетын финанслау чыганакларын маддәләр буенча санау;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, алар тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставка туры китереп билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

13. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты проектын төзү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 171нче маддәсенә туры китереп, федераль кануннар, аларга туры китереп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп Район Башкарма комитеты тарафыннан тормышка ашырыла.

14. Район Башкарма комитеты алдагы финанс елына һәм планлы чорга Район бюджеты турында карар проектын шушы елның 15нче ноябреннән дә соңга калмыйча Район Советы карап чыгуына кертә.

15. Алдагы финанс елына һәм планлы чорга, Район Советы муниципаль хокук акты белән билгеләнгән, Район бюджеты турында карар проектын карап чыгу һәм аны раслау тәртибе, әлеге  проектны карап чыгу һәм аны раслауны, алдагы финанс елы һәм планлы чоры башланганчы тәэмин итергә тиеш.

16. Район бюджеты турында карар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм (яки) Район бюджеты турында карар  белән башка нәрсәләр каралмаган булса, 1нче гыйнвардан көченә керә һәм финанс елының 31нче декабренә кадәр гамәлдә була.

Район бюджеты турында карар билгеләнгән вакытта рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга тиеш.

17. Районның җирле үзидарә органнары Район бюджетының баланслылыгын  һәм федераль кануннар һәм  Татарстан Республикасының кануннары билгеләгән  бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча, бюджет процессын тормышка ашыру буенча, дефицит күләме, муниципаль бурычның күләме һәм структурасы, Районның бюджет йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә.

18. Муниципаль берәмлекләр, бюджетларында Татарстан Республикасы бюджетыннан булган бюджетара трансфертлар күләме (субвенцияләрдән тыш) һәм (яки) өстәмә норматив кучерүләр буенча салым керемнәре  соңгы ике яки өч финанс  еллары эчендә җирле бюджетның үз керемнәре

күләменнән 70 процентка  артып киткән булса, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына туры китереп, бюджет акчаларын нәтиҗәле куллануны күтәрү һәм җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәренең керүен арттыру буенча чаралар турында килешү төзи.

19. Район бюджеты керемнәре Россия Федерациясе бюджет кануны белән, салымнар һәм җыемнар турында кануннар белән һәм башка мәҗбүри түләүләр турында кануннарга туры китереп формалаша.

20. Район бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда тормышка ашырыла.

Районның җирле үзидарә органнары Районның чыгымнар йөкләмәләренең реестрын Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре белән туры китереп һәм Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә алып бара.

21. Район бюджеты чыгымнарын тормышка ашыру, федераль кануннар һәм Татарстан Республикасының кануннары билгеләгән очраклардан кала, дәүләт властеның федераль органнары вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарын финанслауга рөхсәт ителми.

22. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп тормышка ашырыла.

Районның капиталь салымнар программасына кертелгән, смета бәясе 1000000 сумнан артып киткән инвестиция проектлары белән муниципаль милекнең капиталь төзелешенең бюджет инвестициясен тормышка ашыруга бюджеттан акча бүлеп бирү, Район бюджеты турында карарда һәр инвестицион проект буенча аерым чыгымнар булып чагылыш таба.

Районның капиталь салымнар программасына кертелгән, смета бәясе 1000000 сумнан артып киткән инвестиция проектлары белән муниципаль милекнең капиталь төзелешенең бюджет инвестициясен тормышка ашыруга бюджеттан акча бүлеп бирү Район бюджетының җыелма бюджет исемлегендә һәр инвестицион проект буенча аерым чыгымнар булып чагылыш таба.

23. Югары Ослан муниципаль районында бюджет процессы бюджет процессын җайга салучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннары белән катгый туры китерелеп тормышка ашырыла.

**98нче маддә. Муниципаль характердагы урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә тотылган чыгымнар**

1. Район составына кергән җирлекләр Район бюджеты чыгымнарын тормышка ашыру өчен муниципаль характердагы урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә акчалата ярдәмне түбәндәге максатларда күчерәләр:

федераль кануннар белән туры китереп, Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә урын өчен әһәмиятле булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шулай ук автомобиль юлларын куллану өлкәсендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыру һәм юл эшчәнлеген тормышка ашыру;

Район чикләрендә җирлекләр арасында халыкның транспорт хезмәтен оештыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру;

Район территориясендә (Россия Федерациясе раслаган федераль округлар башкарма властена караган медицина учреждениеләрендә медицина ярдәменнән файдаланучы территорияләр санына кергән җирлек территорияләреннән кала) амбулатор- поликлиник, стационар – поликлиник һәм больница учреждениеләрендә беренчел медик-санитар ярдәм, хатын-кызларга йөклелек вакытында, бала табу вакытында һәм тапканнан соң ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне оештыру;

көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын юкка чыгаруны һәм эшкәртүне оештыру өчен.

2. Күрсәтелгән бюджетара акчалата ярдәмнең күләме Район Советы карары белән раслана һәм җирлекләрнең сайлап куелган вәкаләтле органнарының Районның барлык тиешле җирлекләре өчен бертөрле булган нормативлар буенча җирле бюджет муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы карарлары белән раслана.

3. Җирлекнең җирле үзидарә органы Район Советының Район бюджеты турында карарының Район бюджетына бюджетара акчалата ярдәм итү очрак турындагы өлешен үтәмәгән очракта, бюджетара акчалата ярдәм итү күләме, Россия Федерациясе финанс Министрлыгы урнаштырган гомуми таләпләрне саклап Районның Финанс-хисап Палатасы билгеләгән тәртиптә, федераль салымнар һәм җыемнардан кергән керемнәр хисабына, җирле бюджетка күчерелергә тиеш булган салым режимы белән каралган салымнар, региональ һәм җирле салымнар хисабына бюджетара акчалата ярдәм итү түләтелә.

**99нчы маддә. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу Россия Федерациясенең муниципаль һәм дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы канунына туры китереп башкарыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, хезмәт, ярдәм сатып алу Район бюджеты чаралары хисабына башкарыла.

**100нче маддә. Район гражданнарының үзара салым чаралары**

1. Гражданнарның үзара салым чаралары ул аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне чишүне тормышка ашыру өчен гражданнарның бер тапкыр түләүе. Гражданнарның үзара салым тәртибендә түләүләрнең күләме, алар өчен түләү күләме киметелгән, Район гражданнарның (халкының) гомуми санының 30 процентыннан артып китмәгән аерым гражданнар категорясеннән кала, Районның һәр гражданины (яки халкы) өчен тигез күләмдә билгеләнә,

2. Әлеге маддәнең 1нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

3. Җирле референдумның гражданнарның бер тапкыр түләүләр җыю турындагы карары басылып чыкканнан соң Районның Башкарма комитеты:

- гражданнарның үзара салым акчаларын туплау өчен федераль казначылыкта махсус хисап счёты ача;

- референдум карары белән күздә тотылган эшләрне башкаруны оештыра, һәм аларның үтәлеше турында Район гражданнары (яки халкы) алдында әлеге карар белән күздә тотылган тәртиптә хисап тота.

4. Гражданнарның үзара салымы Район бюджетының үз керемнәренә керә.

**101нче маддә. Районның муниципаль үзләштерүе (муниципаль бурычы)**

Район муниципаль үзләштерүене тормышка ашырырга хокуклы, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Район Уставы белән туры китереп муниципаль кыйммәтле кәгазьләр чыгару юлы белән тормышка ашырырга хокуклы.

**102нче маддә. Бюджет отчёты. Район бюджеты үтәлешенең еллык отчёты**

1. Районның бюджет отчёты еллык булып тора.
2. Районның бюджет отчёты бюджет чараларының тиешле төп администраторларының җыелма бюджет отчёты нигезендә Районның Финанс-хисап Палатасы тарафыннан төзелә һәм Районның Башкарма комитетына тапшырыла.
3. Район бюджетының үтәлүе турында еллык отчёты Район Советы карары белән расланырга тиеш.
4. Район Советына тәкъдим иткәнче, Район бюджетының үтүлүе турында еллык отчёты төп администраторларының тышкы бюджет отчётын һәм Район бюджетының үтәлеше турында еллык отчётына йомгак ясауны үз эченә алган эчке тикшерү узарга тиеш.

Район бюджетының үтүлүе турында еллык отчётын эчке тикшерү әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп Районның Контроль – хисап органы тарафыннан тормышка ашырыла.

Җирлекнең сайлап куелган органы мөрәҗәгате буенча җирлек бюджетының үтүлүе турында еллык отчётын эчке тикшерү Районның Контроль – хисап органы тарафыннан тормышка ашырыла.

5. Районның Башкарма комитеты аңа нәтиҗә әзерләү өчен Район бюджетының үтүлүе турында отчётны шушы елның 1нче апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра. Район бюджетының үтүлүе турында еллык отчётка нәтиҗә әзерләү төп администраторларының бюджет акчаларын еллык бюджетын тышкы тикшерүе мәгълуматлары нигезендә 1 айдан артмаган вакыт эчендә үткәрелә.
6. Район бюджетының үтәлеше турында еллык отчётына йомгак ясау Районның Контроль – хисап органы тарафыннан, бер үк вакытта Районның Башкарма комитетына юнәлтелеп , тәкъдим ителә.
7. Районның Башкарма комитеты ел саен шушы елның 1нче маеннан да соңга калмыйча Район Советының карар проекты кушымтасы белән отчётлы финанс елы өчен Район бюджетының үтүлүе турында, Район бюджетының үтүлүе турында башка бюджет отчёты, Районның консолидированный бюджетының үтүлүе турында бюджет отчёты һәм Россия Федерациясе

Бюджет кануннары белән каралган башка документларны Район Советына тапшыра.

9. Район бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын карап чыгу нәтиҗәләре буенча Район Советы Район бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын раслау турында яки кире кагу турында карар кабул итә. Район бюджетының үтәлеше турында еллык отчётын Район Советы кире каккан очракта, мәгълуматларның тулы булмаган яки дөрес булмаган фактларын бетерү өчен һәм 1 айдан да соңга калмыйча кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

10. Район бюджетының үтәлеше турында карар белән Район бюджетының гомуми керемнәре, чыгымнары һәм дефицит күләмен күрсәтеп, отчёт финанс елы өчен Район бюджетының үтәлеше турында отчёты раслана. Район бюджеты үтәлеше турында еллык отчётын раслау турында Район Советының карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

бюджет керемнәренең классификация кодлары буенча Районның бюджет керемнәре ;

бюджет керемнәренең керем төрләренең кодлары буенча Районның бюджет керемнәре, керемнәренең кече төрләре , бюджет керемнәренә караган дәүләт идарәсе операция секторларының классификациясе;

Районның бюджет керемнәре идарә тармагы структуралары буенча Районның бюджет керемнәре;

бюджет керемнәренең классификациясенең бүлекләре һәм кече бүлекчәләре буенча Районның бюджет керемнәре;

бюджетларның дефицитын финанслау чыганакларын классификация кодлары буенча Районның бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары;

төркемнәр, кече төркемнәр, маддәләр, бюджет дефицитын финанслау чыганаклары төрләренең кодлары буенча Районның бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары;

бюджет дефицитын финанслау чыганакларына караган дәүләт идарәсе операция секторларының классификациясе.

**103нче маддә. Районның җирле бюджеты үтәлеше**

1. Районның җирле бюджеты үтәлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп тормышка ашырыла.

2. Район бюджеты кассаның гомуми булуы нигезендә һәм чыгымнарның исәптә булу нигезендә башкарыла.

3. Район бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, Район бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счётын ачу һәм алып бару Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

**104нче маддә. Муниципаль финанс контроле**

1. Муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет канунын һәм башка бюджет хокук бозуларны җайга салучы норматив хокук актларын үтәүне тәэмин итү максатыннан тормышка ашырыла.

Муниципаль финанс контроле эчке һәм тышкы, алдагы һәм аннан соңгы була ала.

2. Бюджет хокук бозулар өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Югары Ослан муниципаль районы Контроль – хисап Палатасы белән тормышка ашырыла.

3. Бюджет хокук бозулар өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Федераль Казначейство, районның Финанс-хисап Палатасы, бюджет акчаларының төп администраторларының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Алдагы муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет системасының бюджеты үтәлгән вакытта бюджет бозылуларын кисәтү һәм булдырмый калу максатыннан тормышка ашырыла.

5. Аннан соңгы муниципаль финанс контроле, аларның үтәлеше, учёт һәм хисап законлы икәнен билгеләү максатыннан, Россия Федерациясе бюджет системасының бюджеты үтәлеше нәтиҗәләре буенча тормышка ашырыла.

6. Муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет кодексы билгеләгән вәкаләтлекләр кысаларында тормыша ашырыла.

## XVнче бүлек. Районның Уставын кабул итү. Бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.

### 105нче маддә. Районның Уставы проектын әзерләү тәртибе, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.

1. Бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында
Район Уставы проекты, Район Советы карары проекты Район Советына Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, иҗтимагый территориаль үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Район Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен Район Советы карары белән махсус комиссия төзелә ала. Әлеге комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары белгечләре, экспертлар чакырыла ала.

3. Район Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты, аларны Район Советы карап чыккан көнгә кадәр, кануннарга туры китереп Район Советы билгеләгән тәртиптә әлеге Устав проекты буенча тәкъдимнәрне, гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен исәпкә алып рәсми рәвештә бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокук акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, шулай ук гражданнарның аны тикшергәндә катнашу тәртибен, Район Уставын Россия Федерациясе Конституциясе белән туры китереп әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта рәсми рәвештә бастырып чыгару кирәкми.

4. Район Уставы проекты буенча Район Советының бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарын Район Советында карап чыгу алдыннан бу Уставның 15нче маддәсенә туры китереп халык алдында тыңлаулар үткәрелә.

**106нчы маддә. Районның Уставын кабул итү, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе.**

1. Район Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын Район Советы Район Советы Регламенты белән туры китереп икедән дә ким булмаган укылышта тормышка ашыра.

2. Район Уставы проектын, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын кабул иткәннән соң, беренче укылышта әлеге проект Район Башлыгы тарафыннан Район Советы депутатларына, әлеге Уставның 69нчы маддәсенең 1нче пунктында күрсәтелгән хокукиҗат инициативасы бирелгән башка субъектларга җибәрелә.

3. Район Уставы, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар Район Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән ике өлешендәге тавыш белән кабул ителә.

**107нче маддә. Район Уставының, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарның көченә керүе.**

1. Район Уставы, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар федераль кануннар белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлекләрнең уставларын регистация үткәрү өлкәсендә федераль органның вәкаләтле башкарма власте территориаль органында дәүләт регистрациясен узарга тиеш.

2. Район Уставы, бу Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар дәүләт регистрациясен узаганнан соң, муниципаль берәмлекләрнең уставларын регистация үткәрү өлкәсендә федераль органның вәкаләтле башкарма власте территориаль органында дәүләт регистрациясен узганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә тиеш).

3. Район җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үзгәртүче Район Уставына керткән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, Район Уставына әлеге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокук актын кабул иткән Район Советы вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң көченә керә.

4. Районның контрль- хисап органы барлыкка килүне күз алдында торган Район Уставына керткән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, гамәлдәге канун белән каралган тәртиптә көченә керә.